Кәүсәрия Шәфикова

# ҖАН АВАЗЫ

Нәсерләр





*Авыруым алдында*
*башымны имичә,*
*тормышка гашыйк булып,*
*кулыма каләм алдым,*
*Мин шуның белән бәхетле!*

## БЕЗНЕҢ ОКТЯБРЬ
(Нәсер)

Коллык богауларын өзеп ташладың син, Октябрь! Инде беркайчан да, беркемгә дә кол булмаячак безнең халык. Бил бөгеп байга хезмәт итүләр, иза чигүләр, фәкыйрьлек –безнең заман һәм бездән соң туачак яңа буын кешеләренең төшенә дә кермәячәк. Ул коточкыч авыр заманнар тик тарихта яшәп калачак. Тарих битләрен актарганда, авыр язмышка дучар булган халыкның моң-зар авазы, коллык богаулары чыңы һаман ишетелеп торачак.

Байрак булып җилфердисең син, Октябрь! Халык кулы байракны нык тота һәм ул шушы килеш, 70 ел буе алга бара, яңа юл сала, яңа тормыш кора. Байракны тартып алмакчы булып пычрак куллар сузыла, юк, аны беркем дә тартып алып, аяк астына салып таптый алмаячак. Азатлык өчен көрәшкәннәрнең йөрәк ялкынын хәтерләтеп ал байрак мәңге җилфердәр. Ирек мәйданы итеп колачыңны җәйдең син, Октябрь, халык күкрәген тутырып иркен сулыш ала. Ул – укый, белем үрләренә күтәрелә, яраткан эшен эшли, иҗат итә. Уйнап-көлеп, җырлап, биеп яши. Хыяллары артыннан бара-бара, инде йолдызлар иленә, ерак галәмгә аяк басты кеше. Ул бүген җиргә дә, күккә дә хуҗа. Октябрь булганга – кеше бөек, акыллы һәм көчле, дөнья иминлеге өчен көрәшә, тынычлыкны яклап тавыш бирә! Таң булып аттың, тормыш күгенә кояш булып күтәрелдең син, Октябрь! Синең яктыңны кара болыт пәрдәләре каплый алмас, син халык күңеленә иңгән нур. Җир йөзендә яшәү дәвам итсен өчен, кеше күңелендәге шушы изге яктылыкның һәрчак балкуы кирәк. Кешелек тормышында шатлык булып, бәйрәм булып яшә, Октябрь! Бөек юлбашчыбыз Ленин тудырган Октябрь син, халык тудырган

Октябрь! Туган көнең бәйрәменә чиксез куанычлар, хезмәт җимешләре белән киләбез, Октябрь!

Күп еллар язылган әйберем бу, әйе, тормыш нык үзгәрде, үзгәртеп кору нәтиҗәсе бу. Октябрь яулаган матур тормышыбыз күгендә кара болытлар күреп күңел сызлана. Октябрь байрагын алып ташлап, яңа тормышта ни күрәбез – элеккегә караганда да ныграк эчкечелек, вәхшилек, наркомания, эшсезлек! Күңел шуңа сөенә, безнең Яңавыл шәһәре түрендә В.И.Ленинның һәйкәле тора, аңа беркем дә пычрак кулын сузмый, 7 ноябрьне һаман да бәйрәм итеп күреп безнең халык һәйкәлгә чәчәк бәйләмнәре сала. Тарих мәңге сакланырга тиеш, хәзерге яшьләребезне тарих белән тәрбияләргә кирәк. Минем канкардәшем, мәктәп укучысы Ленинның кем икәнен белми, рәсеменә карап танымый. Ә бит Ленинны балалар бакчасына йөрүче кызлар да, малайлар да белергә тиеш, әгәр ул белми икән – аңардан ни көтәсең, ул киләчәк тормышта нинди гүзәллек иҗат итәр, хезмәт кешесе, илгә тынычлык теләүче булырмы ул? Без, өлкәннәр, шул хакта уйлап яшәргә тиешбез, “Безнең Октябрь!” – дип әйттем мин бу язмамда, сүзем хактыр, минем туганнарымның балаларының балалары да минемчә уйлап яшәсеннәр иде. Тарихны хөрмәт иткән кеше киләчәгенә якты карашлы була!

**Кәүсәрия ШАФИКОВА**.

(15 сентябрь, 1987 – 13 апрель, 2006 ел).



# УЙЛАРЫМ ДӘРЬЯ
(Нәсер)

Бүлмәгә таң яктысы тулгач күзләремне ачтым да: “Аллага шөкер, төнге сәгатьләр йокы белән, иминлектә үтте, хәерле көн тусын, Ходаем, исәнлек бир!” –дип кинәнеп әйтеп куйдым һәм уйларым белән бик еракка киттем. Мин сугыштан соң туган кеше, үз күзләрем белән ул кот очар хәлләрне күрмәдем, кан-ут эчендә булмадым, ачыгып шешенмәдем, сугыш яланында якын кешемне югалтып яшь түкмәдем. Әйе, ул еллар үткән иде, минем кулсыз, аяксыз абыйларны, тол апаларны гына күргәнем булды. Бәхетле җаннар килгәнбез, тормыш көйләнә бара иде инде, әнкәй белән әткәй яшь колхозчылар, эше булганның ашы да булган! Күз алдында төзелде, яңартылды тормыш, иген үсте, мал-туар үрчетелде, укып төрле һөнәргә ия булучылар күбәйде, гөрләп яшәү дәвам итте, һаман да яшәгәннәр яшибез. Кемдер шөкер итә белә, кемдер зарлана, әй, дөньяда кем генә юк! Мин сәламәтлегем булмау сәбәпле, авырлыклар күп күргәнгәме, тәрәзәм төбендә гөлләрем чәчәк атканын күреп тә шатланам. Әй, бар да шулай булса, кояшлы көненә куанып чәбәкәй итәр иде дә, тормышның ямен арттырыр иде!

Көн яктыра бара, кояш нурлары белән битемә үрелде, җылы, тал булып яфрак ярасым килеп китте. Әйе, тал-тирәкләргә рәхәт инде бу айда, яз җитте бит, кара каргалар кайтты, бөреләр уяна, назлы җил кагылуы гына кирәк, бөре ачылачак! Тиздән игенчеләр кырга чыгачак, гөрләвекләр, ташкыннар җыры шул турыда сөйли. Күреп туймаслык матурлыгы бар бу дөньяның, ул да булса – җиргә яз килү, яшәрү! Йә, Ходай, матурлыкны күрмәүме, нигә бүгенге зәңгәр күккә кара болыт булып тулалар, җанны көйдерәләр!

Ерак-ерактан, Ирак җиреннән килгән авыр хәбәрләр тетрәндерә. Сугыш тавышын кинолардан гына ишетә идек бит, бүген ул куркыныч шартлаулар, елау, ыңгырашулар чынлап ишетелә, әйе-әйе, ишетелә, күңел тынычлыгын югалтты, уйлар борчулы, күзләр яшьле. Солдат хезмәтендәге ир-егетләребез турында уйландыра, табутларда кайтмасмы алар, исән-имин күрешергә насыйп итәрме Ходай! Ирак ерак булса да андагы сугыш дулкыны күңел ярларына килеп-килеп кагыла, чайкалыплар китәсең. Ямьле язның тып-тып тамган көмештәй тамчыларын күз яшенә тиңлисем килми дә бит, башка чара юк, җир шарыбызда яңа, канлы яралар барлыкка килде, бу котларны очырган төш кенә булмады шул, үлем кораллары хәрәкәттә, чын сугыш бара, чын канкоеш һәм чын яз, берсе шатлык, берсе кайгы, җир йөзендә сугышка урын булырга тиеш түгел! Яз яме белән генә яшәсен иде җир, әле йокыдан гына уяна югыйсә, нигә кирәк ул бомбалар, кемгә кирәк?!

Бүлмәмдә таң яктысы, уйларымда Ирак җире! Юк, кирәкми сугыш, көтеп алган көннәр имин булсын берүк, йокыдан уянып күзне ачкач: “Аллага шөкер, җир йөзендә сугышлар юк!” – дисәм иде иртәгә! Яз гына булсын җирдә, яз гына!

## ЙӨРӘГЕМДӘ ЯЗ ҖЫРЫ

(Нәсер)

Саубуллашып ак кулъяулык болгагандай кыш үзенең кар-бураннары белән урамнарны, урман-кырларны бер урап чыкты да үтеп китте. Язгы кояш нурларына җемелди-җемелди тамчыкайлар тама. Тамчылар тамып кына калмый, бүген алар гөрләвекләр булып ага, тын гына акмый, йөрәгемнең үз җыры булган кебек аның да үз җыры бар, гөрләвекләр алар үсәр чәчәкләр, шаулый-шаулый чайкалыр игеннәр турында

# УЙЛАРЫМ ДӘРЬЯ

(Нәсер)

Бүлмәгә таң яктысы тулгач күзләремне ачтым да: "Аллага шөкер, төнге сәгатьләр йокы белән, иминлектә үтте, хәерле көн тусын, Ходаем, исәнлек бир!" –дип кинәнеп әйтеп куйдым һәм уйларым белән бик еракка киттем. Мин сугыштан соң туган кеше, үз күзләрем белән ул кот очар хәлләрне күрмәдем, кан-ут эчендә булмадым, ачыгып шешенмәдем, сугыш яланында якын кешемне югалтып яшь түкмәдем. Әйе, ул еллар үткән иде, минем кулсыз, аяксыз абыйларны, тол апаларны гына күргәнем булды. Бәхетле җаннар килгәнбез, тормыш көйләнә бара иде инде, әнкәй белән әткәй яшь колхозчылар, эше булганның ашы да булган! Күз алдында төзелде, яңартылды тормыш, иген үсте, мал-туар үрчетелде, укып төрле һөнәргә ия булучылар күбәйде, гөрләп яшәү дәвам итте, һаман да яшәгәннәр яшибез. Кемдер шөкер итә белә, кемдер зарлана, әй, дөньяда кем генә юк! Мин сәламәтлегем булмау сәбәпле, авырлыклар күп күргәнгәме, тәрәзәм төбендә гөлләрем чәчәк атканын күреп тә шатланам. Әй, бар да шулай булса, кояшлы көненә куанып чәбәкәй итәр иде дә, тормышның ямен арттырыр иде!

Көн яктыра бара, кояш нурлары белән битемә үрелде, җылы, тал булып яфрак ярасым килеп китте. Әйе, тал-тирәкләргә рәхәт инде бу айда, яз җитте бит, кара каргалар кайтты, бөреләр уяна, назлы җил кагылуы гына кирәк, бөре ачылачак! Тиздән игенчеләр кырга чыгачак, гөрләвекләр, ташкыннар җыры шул турыда сөйли. Күреп туймаслык матурлыгы бар бу дөньяның, ул да булса – җиргә яз килү, яшәрү! Йә, Ходай, матурлыкны күрмәүме, нигә бүгенге зәңгәр күккә кара болыт булып тулалар, җанны көйдерәләр!

Ерак-ерактан, Ирак җиреннән килгән авыр хәбәрләр тетрәндерә. Сугыш тавышын кинолардан гына ишетә идек бит, бүген ул куркыныч шартлаулар, елау, ыңгырашулар чынлап ишетелә, әйе-әйе, ишетелә, күңел тынычлыгын югалтты, уйлар борчулы, күзләр яшьле. Солдат хезмәтендәге ир-егетләребез турында уйландыра, табутларда кайтмасмы алар, исән-имин күрешергә насыйп итәрме Ходай! Ирак ерак булса да андагы сугыш дулкыны күңел ярларына килеп-килеп кагыла, чайкалыплар китәсең. Ямьле язның тып-тып тамган көмештәй тамчыларын күз яшенә тиңлисем килми дә бит, башка чара юк, җир шарыбызда яңа, канлы яралар барлыкка килде, бу котларны очырган төш кенә булмады шул, үлем кораллары хәрәкәттә, чын сугыш бара, чын канкоеш һәм чын яз, берсе шатлык, берсе кайгы, җир йөзендә сугышка урын булырга тиеш түгел! Яз яме белән генә яшәсен иде җир, әле йокыдан гына уяна югыйсә, нигә кирәк ул бомбалар, кемгә кирәк?!

Бүлмәмдә таң яктысы, уйларымда Ирак җире! Юк, кирәкми сугыш, көтеп алган көннәр имин булсын берүк, йокыдан уянып күзне ачкач: "Аллага шөкер, җир йөзендә сугышлар юк!" – дисәм иде иртәгә! Яз гына булсын җирдә, яз гына!

## ЙӨРӘГЕМДӘ ЯЗ ҖЫРЫ

(Нәсер)

Саубуллашып ак кульяулык болгагандай кыш үзенең карбураннары белән урамнарны, урман-кырларны бер урап чыкты да үтеп китте. Язгы кояш нурларына җемелди-җемелди тамчыкайлар тама. Тамчылар тамып кына калмый, бүген алар гөрләвекләр булып ага, тын гына акмый, йөрәгемнең үз җыры булган кебек аның да үз җыры бар, гөрләвекләр алар үсәр чәчәкләр, шаулый-шаулый чайкалыр игеннәр турында

җырлый-көйли. Кар суы җиргә сеңә. Кардан ачылган урыннарда яшел үлән шыта, умырзая –ак чәчәк сабак суза. Элегә бөре генә бүрттергән агачларга карасаң баш әйләнә, шатлыктан кул чәбәклисе килә, агач ботакларына үрелгән оялар һәм чыр-чу килгән канатлы дусларыбыз анда. Бар да кайтканнар бугай, кайтмый калмаганнар шикелле! Күңел түрендәге шатлыкның иге-чиге юк. Җырлы йөрәгемнең ярсу ритмлы тибеше, ярларын җимереп аккан елга ташкынына барып кушыла. Кышның ап-ак карларына кап-кара эзләрен калдырып үткән көннәр булды. Ул эзләр кар суына әйләнеп инде елгаларда ташый. Шулай агып китсен иде бар кайгы, язгы ташу юып алсын иде бар караларны. Их, шулай булсын иде! Әйе, нәкъ шулай булачак та, язны юкка гына көтми күңел. Кайгылардан арынасы, авырулардан тереләсе килә, җиңелмәс кайгы, китмәс сырхауларга дучар булсаң да, яз җитүгә бар да үзгәрер кебек. Әнә, тәрәзә төбендәге гөлләр язгы кояшка үрелә, тыштагы салкынлык аларга сизелми. Шул гөлләргә карап мин килер шатлыкларны көтәм. Йөрәгемнең җырдан тынып торганы юк, аның җыры: кайгылының сабырлыгы, сагынышканнарның бәхетле очрашуы, үлем көткәннәрнең куанып яшәячәк еллары турында. Менә тиздән берәүгә беренче мәхәббәт булып, ялгызга парын табар пар канат куеп сандугач килеп җитәр. Йөрәгемдә сөю җыры, яз җыры! Язның талгын җилләре, күңелдәге өмет ялкыннарына кагылып –кагылып куя, юк, җил утны сүндермәячәк, ул – яз җиле! Күнел язлардан яктылык көтә!

## ГӨЛЛӘРГӘ СУ СИБӘМ ӘЛЕ…

(Нәсер)

Туган көннәребезне туган-тумача, дус-ишләрне җыеп үткәргәнебез булмады, үзара гаилә бәйрәме итеп зурлап үткәрә идек ул көннәрне. Туган көннәребез җитәрәк: «Ниләр ашыйсыгыз килә? – дип башлый идең, әнкәем. Бәйрәм табыны

син әзерләгән тәмле ризыклар белән тулы була иде. Яз аенда туганнар өчен өстәл уртасына, яшел бөреләре бөртеп кенә килгән агач ботакларыннан букет куела иде, җәй туганнар өчен, әлбәттә, түтәлдән, яки кырлардан өзелгән чәчәкләр. Көз, кыш айларында туучылар да табигать матурлыгыннан мәхрүм калмады, һәр мизгелнең үз яме бар, очкан яфракларын, яуган яңгырларын, ап-ак карларын бүләк итеп кабул итәргә мөмкин. Туган көннәребездә изге теләкләр ишетеп күңелебез дулкынланды, истәлекле матур бүләкләр белән кочагыбыз тулды. Көлдек тә, җырладык та, көнебез дә, төнебез дә кояшлы булды. Син идең ул кояш, әнкәй! Бүген синең туган көнең. Бу көн җитсә: «Әнкәйгә нәрсә бүләк итәргә соң, матур күлмәкләре дә, яулыклары да күп, нинди бүләк сайларга»? – дип уйлаша идек. Уйларыбызны белеп калсаң, «Миңа бернәрсә дә кирәкми, янымда булсагыз шул җиткән, минем өчен иң зур шатлык шул!» – ди идең. Бүләк табыла иде, бәләкәч кенә булса да син аны зур итеп кабул итә идең. Бүләкне кулларыңа алгач безгә бәхет, озын гомер тели-тели шатлана идең. Киң күңелле идең, әнкәем, андагы җылылыкның, яктылыкның чикләре юк иде. «Рәхмәт, әнкәй, бу дөньяга туганың өчен!» – дип әйтә алдым микән! Дөньяга гүзәллек өстәдең син, синең яшәү – тормыш авырлыклары белән көрәш булды, син җиңдең! Зар елаганың булмады, үзеңне бәхетсез ана, дип санап минем күңелемне төшермәдең: «Бар яшәвем синең өчен!» – дип канатлы иттең син мине. Давылларга каршы очар канатларыңны гомер буе иңнәремдә тойсам иде!

Бүген синең туган көнең, әнкәй. Күңелемдә бәйрәм юк, син юк! Кабереңә килдем, үзең утыртып үстергән гөлләреңнең чәчәкле ботакларын алып килдем. Тиз генә шиңмәсеннәр әле, дип, гөлләрне сулы савытка утырттым. «Тәрәзә төбе тулып шау чәчәктә утырган гөлләрне өзмәсәң дә булыр иде, рәшәткәм эче тулы чәчәк бит!» – диясеңдер кебек, әнкәй. Әйе, чәчәккә күмелгәнсең син, тик, шулай да, сине бу көнне бүләксез куясым килмәде, гөлләреңне өзгән өчен гафу ит! Гомерең буена гөлләр үстердең, минем өчен үстердең син

аларны. «Чыгып, кырларда, болыннарда йөри алмыйсың, тирә-ягың чәчәк кенә булсын әле!» – дидең әнкәй. Гөлләр кебек яшәгәндә син авырып киттең. Хастаханәгә китәсе көн бүгенгедәй күз алдымда. «Терелеп кайтуымны теләгез!» – дип гөлләреңә су сибә-сибә әйтүең колагымнан китмәячәк. Чәчләрең кебек ак, яулыгың кебек кызыл,күлмәгең кебек көрән чәчәкле гөлләрең белде микән, ә мин – синең терелмәячәгеңне белә идем шул. Йөрәгем үксеп елады, күзләрем белән синең һәр хәрәкәтеңне күзәтеп, хәтеремдә калдырырга тырыштым. Син минем җанымда яшисең, әнкәй,

«Гөлләргә су сибим әле,
Гөлләрем шиңмәсеннәр.
Гөле шиңгән, ул үзе дә
Шиңәр әле, димәсеннәр.

Бу җырны әйтеп гөлләргә су сибеп йөрүләрең гомерем буе бәгыремне телеп агылыр, бер моңлы җырга әйләнер.

Юк, әнкәй, гөлләрең шиңмәячәк, синең гомереңне дәвам итеп шау чәчәктә утырачак алар. Сине сагынып өзгәләнгән чакларымда син булып гөлләр мине юатачак. «Елап түгел, җырлап яшәргә кирәк!» – диячәкләр. Бу бит синең сүзләрең, әнкәй, бүген синең туган көнең. Күңелемдә бәйрәм түгел, күзләремдә сагыш, яшь. «Елама!» – дигән сүзләрең исемдә генә булса да еламый булдыралмыйм, бигрәк тә бүген. Җыр, чәчәкләр, күз яшьләре – аларсыз яшәп булмый икән. Җырлап яшәрмен, синең кабереңә күз яшьләрем белән, тәрәз төбендә үскән гөл-чәчәкләр белән килермен, әнкәй!

## ӨЗЕЛГӘН ҖЫРЫМ

(Нәсер)

Әнкәйсез булу җиңел хәл түгел, менә шушы авырлык белән көрәшеп яшәвемә 16нчы апрельдә 12 ел тула. Сабый балага әнисе ничек кирәк булса, миңа да әнкәй шулай кирәк иде дә бит, нишләмәк кирәк, Ходай тәкъдирен үзгәртердәй

көч-чара юк, 61 яшендә әнкәмне каты авыру кояшлы дөньядан алып китте. Әнкәйгә багышлап язылган шигырьләрем, җырларым шатлык белән яңгырый иде бит, әнкәйсез калгач алай түгел, җырлар үксеп елый, алай гына да түгел, җырлар өзелеп кала. Өзелгән җырны ялгап булмый, дәвамы – күз яше, кайгы, сагынып әрнү! Әнкәй кеше кайгылы чакта да, шатлыкларың зур булганда да бик кирәк, иң газиз, иң кирәкле, иң ышанычлы кешең ич ул, сине, кадерле баласын, күз алмасын җил-давылларга бирмәячәк! Әнкәм соңгы сулышына кадәр минем өчен шатланды һәм хәсрәтләнде, ана йөрәге баланы сөеп туймый! Әйе, каты бәгырьле аналарның да барлыгын беләм мин, тик аларны, камил акыллы түгелләрдер, дигән уй белән тынычланам, югыйсә, күзенә карап ярдәмен көткән гарип баласын хөкүмәт тәрбиясенә бирә алыр идемени! Ә инде, чүплектә табылган нарасыйларның аналары турында уйлыйсы да юк!

Гәзит битләрендә: "Әни мине яратмый, мине аңларга теләми, фәлән егет белән очрашып йөрүемә каршы!" – дигән яшь кызларның язмаларына тап булам да юк, әнисен түгел, кызның үзен гаеплим, нигә ул аны гәзиткә язып ята, үзара аңлашып була бит! "Әниләрнең әйткәннәре күп вакыт дөрескә чыга, аларга үпкәләү зур хата, бер үпкәләгәнче ун кабат уйлап карарга кирәк, әти-әниеңне рәнҗетергә хакың юк, синең ачу тотуың-үпкәләвең бигрәк тә анаң күңелен җәрәхәтли, бала буларак моны исеңдә тотсаң иде!" – дип әйтәсем килә. Әнкәйләр алар артыгы белән йомшаклар, шуннан файдаланып ни генә кыланмый баласы, белә шул, ана гафу итәчәк! Балага авырлык килсә тәүдә ана йөрәге ярлана, ул ут йота, үзе ашамый, баласына каптыра. Шулай яратылган ул, җаны гел тетрәнеп торыр өчен ана булган. Кызы өчен дә, улы өчен дә бер үк төрле борчыла әнкәйләр. Сабый чагында да бала ана өчен кадерле, газиз, иллегә җитсә дә шул ук караш, "Балам!" – дип өзгәләнә. Үсмерләргә шуны әйтер идем; бала булуыңның кадерен бел, иркәлән, тик акылыңны җуйма, әниеңне алдама, син аны түгел, үзеңне алдыйсың, иманыңа хыянәт итәсең, бу

исә төзәтеп булмый торган хата! Кызлар – әни, егетләр әти булачаксыз, рәхмәт, дога алырга тырышыгыз, бүгенгесе белән генә түгел, киләчәк тормыш өчен бүген үк әзерлек алып барыгыз, бәхетле булырсыз. Әниләр күңеле бәллүр, ватылмасын, сак булыгыз, саксызлык –гомерлек үкенү ул, үкенү газаплы, бу авырлыкка дучар булмагыз!

Әнкәйсез калгач кояшның җылысы да, яктылыгы да кимеде кебек. Димәк, дөньяда әниле булу иң зур бәхет, кояш кояш кына булып кала! Әнисезләр аңлый мине, кичерешләребез уртак, бер үк төрле сагынабыз. Әнкәй кебек эндәшмиләр, әнкәй кебек якламыйлар, әнкәй кебек юатмыйлар, әнкәйне алыштыра торган беркем юк. Өзелгән җырым мине гомер буе моңлы итәр!

## ЯФРАК ЯҢГЫРЫ

(Нәсер)

Алдыма сары күбәләк килеп кунды дип торам, каен яфрагы икән. Яшел яфраклар арасында сарылары да күренә башлады шул, берсе әнә алдыма ук килеп төште. Күптәнмени әле бу сары яфракның ямь-яшел бөре булып, кояш җылысына төренеп ботакта тирбәлүенә, и гомер дигәнең, саргаеплар кибәр чагы җиткән! Яфрак кына дигәч тә, күргәндер инде ул, җәй буена аз булмагандыр, җиле исә, яңгыр ява, кояш кызуы, тузан, боларның берсе дә яфракларны читләп үтми, рәхәтен дә, кыенын да күрә алар. Сары яфракны кулларыма алам, каен яфрагы матур, юк, мин аны кабат искән җилгә бирмим, шигырьләрем язылган дәфтәр арасына салып куярмын, яңа шигыремә әйләнер әле ул, җыр булып яшәр! Сары яфраклар очкан чакны яратам, яфрак яңгырын җылы, кояшлы яңгырга охшатам, күңелемне иркәли шушы мәл, наз белән тула дөньям, рәхәт тойгы кичерәм, ялкынланып иҗат итә башлыйм, күзләр мине өшетми, әйтәм ич, мин ялкынлы! Күзләрдә җылы

аз булса да җыр күбрәк сыман, кулымдагы сары яфрак ниләр генә сөйләми дә нәрсәләрне генә искә төшерми, юк, ул үле түгел, саргайган гына, яфрак минем сагышыма әйләнә, моңым булып җаныма сарыла. Каенның сары яфрагын көзнең шаян җил малае ботактан өзеп алды да алдыма китереп салды, юк-юк, алай түгел, сөйгән ярымны сагынуым каен яфрагына әйләнгән, күзләремдәге яшь ул сары яфрак. «Син генә сагынмыйсың, сөйгәнең дә сине сагына. Сагына, сагына!» Каеннан очкан яфраклар шулай дип тавыш бирәләр, мин аларны ишетәм, үзгә булган телләрен дә аңлыйм. Әйе, сагыну газаплары белән өтелеп яши кеше, еракта булган сөйгән яр, туганнар, дуслар, дөньядан киткән якыннар сагындыра. Сагыну яралары күп миндә, тирән уелганнар, төзәлерлек түгел. Моннан тугыз ел элек дөнья куйган әнкәмне сагыну бигрәкләр дә авыр газаплы, агачлар яфрак ярганда да, яфрак койганда да сагынам. Язның, җәйнең гүзәл чәчәкләрен, көзнең алтын яфракларын бер тотам итеп җыя иде дә: «Күр әле, нинди матурлар!» – дип алдыма китереп сала иде. Әнкәй минем рәсемнәремне яратып карый иде, әткәй алып кайткан буяуларны янымa куя да: «Шушы сары яфракларга карап көзге урманны сурәткә төшер, бик матур чыгачак!» – ди. Кояшлы көннәрдә коляскамны этеп урамга алып чыга, яфрак бураннары әй, матур! Көзләрем һәрчак илһамлы булды. Сагынам, әнкәйле көзләрне сагынам! Мин хәзер кулыма буяулы пумала тотып рәсемнәр ясый алмыйм, кулларым көчсез, рәхмәт әнкәмә, табигать ямен бүләк иткәне һәм мине рәссам итеп күргәне өчен. Инде көзнең, кызарып пешкән балан, миләш тәлгәшләрен, алмаларын, чияләрен, сары яфракларын, яңгырларын җилләрен, һавадагы торналарны, кыр казларын шигырь итеп ак кәгазьгә күчерәм. Яфраклар турында күп язам, бүген дә алдыма очып төшкән сары яфрак минем тынычлыгымны, күңелем кылларында өздереп - өздереп моң чиртте. Табигатьнең көчле булуы бу, сары яфрагы гына да ни кыландырмый җанны!

Шулай да көзне «Моңсу!» димим, көз аенда елап тусам да һәр мизгелдә матурлык күрә белеп яшәргә насыйп иткән Ходай, көзләрдән карыныма да, рухыма да азык алам!

## ТӨН
(Нәсер)

Кыз көндәлек дәфтәренә күңел серләрен күчерә. Хисләр шундый ярсу, язлар ташкыны кебек, һич тыярмын, димә. Үзе ярсу, үзе кайнар бу яшьлек хисләре, дөнья тулып шаулый. Санап бетергесез зәңгәр йолдызлары, тулган ае, кояшы бар ул дөньяның, анда ай да, кояш та, йолдызлар да, ак болыт та, очкан кош та, җилләр дә, чәчәкләр дә сөйләшә. Андагы көлүләр дә, елаулар да кабатланмас матурлык! Яшьлек дөньясы ул! Яшьлекнең хыяллары да үзгә, хыял күге һәрчак аяз, җилләре генә түгел, давылы да назлы, ягымлы. Юлларда киртәләр очрамый анда, таулар сине үзенә дәшә.

Кыз дәфтәрнең ап-ак битенә үзенең якты тойгыларын яза: «Кадерлем! Әйе, син миңа бик кадерле, тик әле бу сүзне үзеңә әйткәнем юк, оялам! Оялам шул мин, күз карашларыбыз очрашканда шундый кызарам, тәнем уттай янып китә. Син кичә: «Яратам!» дидең, ә мин әйтә алмадым. Оялдым! Әйтермен әле, иртәгә, матур күзләреңә тутырып карармын да: «Мин сине яратам!...» – диярмен. Син ачуланма миңа, бүген очрашырга чыга алмадым, әнкәем авырып китте, әткәем өйдә юк бит, командировкада. Иртәгә, әнкәйнең хәле яхшырса, чыгармын, коштай канатланып яныңа ашыгырмын. Бүген сагынып көткән идеңме, колачыңны җәеп көттеңме? Беләм-беләм, әйтмәсәң дә беләм, син мине көттең. Бәлки, әле син безнең өй янында, кичә икәү бергә утырган сикедә минем чыкканымны көтеп утырасыңдыр. Менә әле мин дә тәрәзәдән тышка карадым, караңгы, берни дә күренми. Августның уртасы шул инде! Әнкәем дә йокыга талды, килеп сызгырсаң, тиз генә чыгып керермен әле, сөеклем! Әйе, мин күңелемнән сиңа шулай дип эндәшәм. Без бит күптән, мәктәптә укыганда ук бер-беребезгә гашыйк. Син унынчы, мин тугызынчы сыйныфта укый идек, озата килдең. Дусларча гына озата идең

кебек, ике ел шулай йөрдек, мин сиңа гашыйк булдым. Син дә миңа гашыйк икән, кыр чәчәкләрен өзеп миңа суздың да: «Син чәчәк кебек матур!» – дидең. Яратуыңны әле кичә генә әйтсәң дә гашыйк икәнеңне шул чакта белдем. «Ышан, мин сине яратам!» – дидең. Ышанам, яратуыңа ышанам, син бит күзләремә карап әйттең! Яратам, дип пышылдавыңны, күз карашларыңны, иреннәрең кайнарлыгын мәңге онытмам! Мәхәббәтебезнең гомер буе шулай, бүгенгедәй саф булуына ышанам мин!

Кыз көндәлек дәфтәрен ябып куйды, сәгатькә карады, төнге бер! Ә егет бу вакытта кунак кызын озата бара иде. Сөйләшәләр, көлешәләр. Менә егет кызны күкрәгенә кыса! Төнге күкнең йолдызлары әйтерсең лә бүген алар өчен генә яна!

**ЯҢА КЕШЕ**

(Нәсер)

(Илгизгә)

Саумы, сабыем! Якты дөньяга туып тавыш бирүеңә әле берничә генә көн, елап тавыш бирсәң дә әле бу чын, үксеп, өзгәләнеп елау түгел, «Мин тудым, дөнья, кабул ит!» – дип аваз бирүең бары. Дөнья сине кабул итеп кочагына алды, әнкәң авыр тулгакларыннан котылып иркен тын алды, ул сине исән-имин таба алуына шатлана, сиңа, газиз балакаена, бәхетле гомер тели. Бала тугач ата-ана, бар туганнар, дус-танышлар шатлана, бәби тәпие юалар, шау-гөр киләләр бар да туу шатлык кына китерә! И бәләкәчем, шатлыкның да, бәхетнең дә ни икәнен белмисең бит әле син, кояшны да күргәнең юк, җилләр дә әле синең чәчләреңнән сыйпап исмәде. Бу дөньяның кояшлы да, болытлы да көннәре бар, ай-йолдызлы һәм караңгы төннәре бар. Сайрар кошларын, буранлы кышларын, умырзаялы язларын, җиләкле җәйләрен

күрерсең әле син. Әле күз ае, син күз аенда, яшел төсен җуеп сап-сары булган яфраклар тирәкләрдән өзелеп очкан чакта тудың, байлык-муллык чоры, басуда икмәк уңды, күңелләрнең күр чагы. Бәхетең зур булыр Аллаһы боерса, киң ризыклы булып яшәрсең, берүк, игелекле бәндә булып тормыш юлыннан атла. Син әле ап-ак биләүдә, кая әле тәпи атлау, икмәк тәме белү, әнкәңнең күкрәк сөте тәмен, әлбәттә, беләсең, сорап елыйсың ләса! Әнә шул сөт үстерә инде, зур булып үсәчәксең! Әле башта елмаерга-көләргә белә башларсың, нәни кулларың белән чәбәкәй-чәбәкәй итеп, аякларың белән тыпырдарсың, «Әттә-әннә!» – дигән беренче сүзләреңне әйтерсең. И, Ходаем, шулай гына була күрсен, телең «Әннә!» – дип ачылсын, татар баласы булып үс, әнкәң бишек тирбәткәндә татар моңын көйләсә һичсүзсез татар булырсың! Әйе, күптөрле милләт кешесе белән яратылган дөнья, һәркем үзенчә матур, үзенчә әйбәт, тормышта ялгышмый да, адашмый да яшәүгә ни җитә!

Сабыем, бу тормышта ак та, кара да бар, яхшылык белән яманлыкны, ямьсезлек белән матурлыкны, бәхет белән бәхетсезлекне аңлата бу ике төс, син ул төсләр белән очрашырсың әле, карасы белән күзгә күз очрашкач куркып кына калма, куркып-шүрләп калдыңмы – син көчсез кеше, тормышны бизи алырлык матурлык бирә алмыйсың, ә кеше гүзәлеккә ия булып, шул гүзәллеген тормышка бирергә тиеш. Әйе, син кеше, яңа кеше, яңа язмыш яралды, син беркемне дә кабатламыйсың! Күп белерсең, күпне күрерсең, күп булыр шатлыгың да, борчулы уйларың да, шуның өчен дә син – кеше! Бар да нәни-бәби була башта, күз аенда тусаң да ямь-яшел булып борын төрткән үлән генә әле син, гөл булып кояшлы зәңгәр күккә үрелерсең, чәчәк атып орлыгыңны өлгертерсең, дәвамың ялалыр, син үзең дә бит әткәң-әнкәңнең дәвамы булачаксың, бу дөньяда үлем дә бар, үлем – коточкыч! Юк-юк, ул турыда сүзне туктатам, без яшәү турында гына сөйләшик, дөресрәге, мин сөйлим, син тыңла, тыңла, мин сиңа уйларымда эндәшәм, уйларымда тормыш

җыры көйлим. Бер гөнаһсыз сабый, татлы йокыга талдың, хәзер-хәзер, сүзләремне түгәрәклим, син тыныч йокла, әнкәң дә ял итсен, күкрәгенә сөт төшсен, йокыңнан уянгач тамагыңны туйдырырсың. Йокла, кан-кардәшем, без сине ашкынып көтәбез, берничә көннән бала тудыру йорты янына җиңел машина барып туктар, әткәң сезне алырга барыр, матурлыгы белән күзләрне иркәләгән чәчәкләр бәйләмен әнкәңә бирер дә сине beləгенә алыр. «Киләчәктә, картайган көнебездә ышанычыбыз булсаң иде, балакай!» – дип әйтер ул күңеленнән генә, син аны ишетергә тиешсең, сиңа яшәү биргән ата-анаңның йөрәк сүзләре бу!

## ЯСАЛМА ЧӘЧӘКЛӘР

(Нәсер)

Быел да яз бәйрәме 8нче март белән котлап күпләр чәчәк бүләк итте. Чәчәкләрнең сулы савытта утырганнары инде төсләрен җуйды, кибеп чүпкә әйләнде, минем өстәлемдә юк алар, ә гүзәллекләре күңелемдә яшәп калды, рәхмәт, тере чәчәкләр бүләк иткән дусларыма, дуслар бүләк иткән гөлләр мәңге сулмый ул! Ясалган чәчәкләр бүлмәмне ямьләп бүген дә өстәлемдә утыра, шундый матурлар алар, күреп күзләр туймый. Ясалган чәчәкләрнең кызылы да, зәңгәре дә, агы да, алы да бар, бар да миңа елмая. Әйе-әйе, ясалма чәчәкләр елмая, минем күңелем терелтә бит аларны, тере чәчәкләр карый миңа, әйтерсең лә, алар түтәлдә, кояшка үрелеп, назлы җилдә тибрәлеп шатланалар! Рәхмәт сезгә, чәчәк бүләк итүче якыннарым, ясалган чәчәкләргә бигрәк тә сокланып багам мин, тере чәчәкнең гүзәл сыны бит алар, җанны иркәли торган сихри көч анда.

Мин матурлыкка табынам, шуңа да, ясалма чәчәкләрне җанлы итеп күрәм, мин алардан күзләремне алалмыйм, алар белән сөйләшәм, серләшәм, чәчәкләр матурлыгы мине әсир

итә. Чәчәкләргә карыйм да кешеләр турында уйлыйм, кеше матурлыкны тоя, күрә һәм куллары белән аны эшли. Табигать тудырган гүзәллекне теләге, тырышлыгы белән кабатлый ала кеше, әйе, ясаган чәчәкләренә җан өрәлми ул, җан өрәлмәсә дә җанлы итеп күрә белә! Бүлмәм чәчәкләр белән бизәлгән, нинди генә чәчәкләр юк, аллы-гөлле булып ямь бирә алар, күңелемдә һәрчак яз! Мин кеше, миңа матурлык, сөю, шатлык кирәк, чәчәкләрдә алар бар, чәчәкләрдә – тормыш үзе! Әйе, чәчәкләр белән яшәү – ул бәхет! Мин тирән уйларга чумып бәхет турында фикер йөртәм, чәчәкләргә карап сорау бирәм: “Чәчәкләр, ничек сез шулкадәр матур?” Җавап ишетәм: “Кешеләр күңелендәге матурлык безгә күчкән!” Уйларның чиге юк, йөрәк дерт итеп китә, чәчәкләрнең ясалган гына булуы тетрәндерә. Ясалма матурлык та бар бит кеше күңелендә, андый матурлык җаннарны җәрәхәтли. Бәхетле булыр өчен чын матурлык кирәк, тере булсын ул матурлык, ясалма-ялган булмасын! Өстәлемдә ясалган чәчәкләр, мин аларны тере итеп күрәм, ничек шулай булмасын, матурлык күрә белүче күңеленнән өзелгән алар, чәчәкләрне алтын куллар, уңган куллар ясаган! Ясалган чәчәкләр, күңелгә шом салмагыз, күңелендә ясалма матурлык йөртүчедән көчлерәк булып яшәргә була, ул көч – үзең ясалма булмауда!

## БҮЛӘК

(Нәсер)

Туган көнең белән котлап чәчәкләр өзәр идем. Бәлки әле өзми генә мин ул гүзәл чәчәкләрне сиңа болыны белән бүләк итәр идем. Көн яктысына үрелеп үскән чәчәкләр үз төсләрен мәңге җуймасын дип мин аларның керфек очларына, тамчы-тамчы таң чыкларын тезәр идем. Мин сиңа, күңелләрне иркәләп искән талгын җил бүләк итәр идем. Җил синең чәчләреңә кагылыр иде, назлап сөяр иде ул сине. Күкнең

зәңгәр күлендә аккошлардай йөзгән ап-ак болытларны да, җылы, кояшлы яңгырны да, яңгырдан соң нур чәчеп калыккан салават күперен дә сиңа бүләк итәсем килә. Туган көнеңне котлап, бөдрә тирәкләрдә тирбәлеп былбыллар сайрасын иде дә, шул изге кошкайларның тавышы мең дәва булып синең җаныңа иңсен иде. Кайгы-хәсрәтләреңне, авырту-сызланулармыңны оныта алсаң иде син! Кыш ае! Күпме генә эзләсәм дә юк, болын чәчәкләре табалмам, җир өстен кар каплаган. Былбыллар да оялы куакларын калдырып еракларга киттеләр, яз җиткәч кенә аларның тавышын ишетү мөмкин булачак. Әле кыш, әлбәттә, кышның да үз яме, үз матурлыгы җитәрлек, күбәләкләр булып очышкан ап-ак карларына гына да ни җитә!

Син кыш аенда тугансың. Энҗеләр булып сибелгән җем-җем кар бөртекләрен бүләк итәргә микән? Ап-ак бәс сарган агачлардан күзләремне алалмыйм, әллә сиңа бүләк итеп шуларны сайларгамы? Ак бураннарга төренеп яныңа килдем әле, кышның ап-ак ефәк җепләрдән чигелгән бөтен матур бизәкләрен күңелемә җыеп алдым да сиңа китердем. Кыш салкын булса да өшетмәс ул сине, җылытыр җылым бар! Бүген синең туган көнең! Шатлыкларың таудай, бәхетең тулган айдай түгәрәк булсын әле, бәйрәмеңә килдем. Сөю белән тулы күз карашым сиңа төбәлгән, минем карашларымны бүләкләрнең иң асылы итеп кабул итсәң иде!

## БҮГЕНГЕ ҖЫР

(Нәсер)

Көзнең дә кояшлы көннәре бар, гел генә күк йөзен болыт каплап, яңгырлар гына явып тормый. Катлам-катлам болыт-пәрдәләрне ачып әледән-әле кояш җиргә бага, түтәлләрдә гөлләр дә бар бит әле, өлгерәсе җимешләр, яшелчәләр бар, бар да кояштан җылы көтә. Без, кешеләр дә: «Кояшлы көннәр булса иде әле, әбиләр чуагы озагракка сузылсын иде!» – дибез,

салкын җилләр исеп яңгыр сибәли башласа эссе җәйне сагынабыз. Көз ае үзгә матур бит ул, ничә төрле буяу анда, агачлар үзләре чәчәк бәйләмен хәтерләтә, яфракларның ничә төрле яшеле, сарысы, кызылы, көрәне бар, яратам яфраклар очкан чакны, җанлы күбәләк кебек бит алар, талгын җил ничек матур итеп тирбәтә үзләрен, җиргә төшеп җиткәнче һавада биеп әйләнәләр, җанга җыр булып иңәләр. Әйе, көзләр миңа җыр бүләк итә, бүген дә җыр-шигырь көтәм. Тирәкләрдән өзелеп очкан яфракларга карап утырам, алма бакчабыз мин утырган күтәрмәгә туры гына, әллә ничә төрле агач-куак анда, бар да яфрак очыра. «Мине җыр итеп ал!» – дип эндәшә кебек балан да, миләш тә, алмасы-чиясе, шомырты да өзелгән яфраклар моңыма әйләнә бара, көзге җил күңелемнең нечкә кылларын чиртеп-чиртеп ала бит! Биеклеккә күтәрелеп әйлән-бәйлән уйнаган кара каргалар да минем моңым, канат ныгыталар, җылы якка китәр чаклары җитә! Китәбез шул, туган җир, оялар кала, минем дә язмыш кошларныкына охшаш. Имин язлар килсен, вакытлыча гына китүләргә түзәбез инде! «Китү!» – дигән сүз үзәкне өзеп алса да мин барыбер көзгә гашыйк булып яшим, көзге муллык күңелне көрәйтә. Басу-кырларга күз салам, әле анда хезмәт шавы гөр килә, уңыш җыю бара, җиткән игенне амбарларга ташыйлар, киләсе ел өчен хәстәрлек күрү башланган, тунга сөрү эше бара. Игенче йоклап ятмый, «Бүген алтын бөртекләрдән тау өелде!» – дип тынычланмый ул, килер көннәр бәхете аның кулында бит! Тиздән халыкка ашлык таратылачак, чын бәйрәмгә әйләнә ул көн, шулай булмыйча, эшче кеше ат йөге белән генә түгел, машинага төяп икмәк ала, пенсиядәгеләр дә читтә калмый, рәхмәт хөкүмәтебезгә, барыбыз да тук яшибез. Көзнең бу матурлыгына тиң матурлык бармы соң?! Чынында көз авыл җирендә матуррактыр ул, кырлардан икмәк, бакчалардан бал, алма исе килә, ул су буенда оя-оя казлар каңгылдашуы, көтүдәге симез мал-туар бар да бездә, авылда бит! Авыл халкы сүз оңгаенда гына «Эш күп!» – дип әйтеп куя да ул, юк, зарланмый алар, мул

тормышта яшиләр, шуңа да зарланып күңелен кара көйдермидер. Яратам көз аен, яшел уҗым басуы гына да ни тора, килер яз төсе бит ул яшеллек! Чү! Мылтык аттылар ич, үрдәк тавышы йөрәкне телеп үтте. Буада кыр үрдәкләре бар иде, яшел камышлар арасыннан чыгып суда йөзгәннәрен үз күзләрем белән күргән идем, шуларны аталар бит, кем ул таш бәгырь, кем ул ерткыч? Әле генә әйттем ич, беркем дә ач түгел, ни күреп шул йодрык кадәр җан ияләренә көпшә төзиләр? Әй, көз ае, көз ае, менә шушындый күңелсезлекләр дә көз аенда була шул, ауга чыгарга рөхсәт ителә! Кулында ау мылтыгы булган кеше читкәрәк китсен иде дә соң, әнә бит, авылыбыз буасында оя корып яшәгән кыр үрдәгенә тукталган. Карыны тук, кызык итеп ата ул үрдәкне, матурлыкны харап итүен аңламый. Әнә, ачыргаланып кычкыра парын югалткан инә үрдәк, иптәшен эзли. Юк шул, табалмас, кеше явызлыгы аерды аларны, үлем аерды! Ялгыз калган кыр үрдәге кычкырып буа өстеннән берничә тапкыр очып әйләнде дә тынып калды, әллә кайгыдан йөрәге ярылды инде бичараның, бу халәткә минем күңел яраланды, әрнеп, күзләрем яшьләнеп күк йөзенә, бактым, анда болыт. Көз ямансу, моңсу төс алды, минем көзне матур итеп кенә күрәсем килә иде, булмады, сагышлы җыр бүләк итте миңа көзнең бүгенге көне, матурлык янында ямьсезлеккә дә урын бар шул.

## КҮКЛӘРЕҢ БОЛЫТЛЫ, АЯЗ!

(Нәсер)

Аяз, син, үзеңнең "Әни!" дип кычкырган тавышыңны ишетеп, уянып киттең. Караңгы, суык, өшегәнсең, башың, башың гына түгел, бөтен тәнең шундый нык авырта, тешләреңне кысып та түзәрлек түгел, үзең дер-дер киләсең, урыныңнан кая инде элекке кебек сикереп кенә торырга, хәлең юк, көч-хәл белән генә кузгалып, авыр таш кисәгедәй

башыңны күтәреп, тирә-ягыңны карадың. Бәләкәй генә тәрәзә сыман җирдән начар гына яктылык сирпелә, нәрселәр барлыгын да күрмисең. Борыныңа авыр ис килеп бәрелде, укшып куйдың. Кая булып беткәннәр соң иптәшләрең, Сашка нигә ташлап калдырган, Ренат кая? Өчәү идегез, ә юк, тагын бер кыз бар иде, Рита исемле иде бугай ул кыз, әйе, исеңә төште, Рита, чибәр кыз иде, Саша алып килде аны, бер сыйныфта укыганнар, "Вот она, вам подарок!" – диде Саша, кызны сиңа этеп җибәрде. Рита эчкән иде, тагын бергәләп эчтегез, аннары кызны чишендердегез, әй, юк, ул үзе анадан тума чишенде дә, бии башлады, "Где музыка?" – дип кычкырды. "Кычкырма, клубта түгелсең!" – дип кызны кочагыңа алдың. Әйе, бары шулар гына хәтереңдә, инде менә калтыранып уяндың, авыз эчең, иреннәрең кипкән. Чалбар кесәңне капшап, шырпы таптың да, кабыздың, бармакларың шырпы бөртеген дә тоталмый, чак кабыздың, шул кыска гына вакытка кабынган ут яктысында тирә-ягыңа карап, шприцлар, шешәләр, ашамлык калдыклары күрдең. Пычранып беткән ак җәймәне ачкан идең, Ренатның зур итеп ачылган җансыз күзләрен күргәч, йөрәгең кубып, кычкырып җибәрдең, подвалдан чыгу юлына таба шуыштың... Аяз, өченче сыйныфта гына укый идең әле, син, биш ел төрмәдә утырып чыккан күрше Гаяз абыең тәкъдим иткән тәмәке төпчеген кире какмадың. "Егетлегеңне күрсәт, йә, кап, суыр!" –диде ул. Үтерер, дип курыккансыңдыр, төпчекне алдың. Көн дә ул синнән тәмәке китертә иде, акчасын да бирмәде, әти-әниеңнекен урлап алырга өйрәтте. "Күрше хакы – Тәңре хакы" диләр, егет кеше, син мине тыңла, кара аны, әтиең сизмәсен, икебезгә дә эләгер, мине тагын төрмәгә утыртырлар!" – дип сине бозык юлга этәрде. Аракы эчәргә дә өйрәтте Гаяз абыең. Үзе беркайда да эшләмәде, гаиләсе дә юк иде. Кеше үтереп төрмәдә булганнан соң үпкә чиренә сабышкан иде ул, өч елдан соң үзе дә дөньядан китте.

Авылдан шәһәргә күчкәч тә дусларың күп булды, Гаяз ише генә дә түгел. Үсә барган саен кара һөнәрләрең дә артты

гына, уку ягың бик йомшарды, сыра эчтең, башың авырта да, мәктәпкә бармыйсың, көннәр буе, төннәр буе телевизор карыйсың, ә анда ни генә күрсәтмиләр!

Әти-әниеңне борчуга салдың, тиргәп тә, хәтта кыйнап та карадылар, син акылыңа килү турында уйлап та карамадың, өйдән чыгып киттең, урлаштың, бакча таладың. Саша да, Ренат та, тагын әллә кемнәр синең якын дустың булдылар, явызлыктан башка берни эшләмәдегез. Ренат наркотик тапты, син дә читтә калмадың. Акча күпләп кирәк була башлады. Каян аласың? – кеше сумкаларын кистегез, ялгыз әбиләрне куркытып, пенсия акчаларын алдыгыз. Әнә, Ренатка әбиләр, башка зыян күрүчеләр рәнҗүе төшкән, үлеп ята, сиңа төшмәс дисеңме, Аяз, сиңа да якынлаша ич ул коточкыч үлем. Күрсәң иде үзеңне, зәңгәр чәчәктәй күзләрең нурсыз калган, әле бер тапкыр да сылу, саф кыз баланы үпмәгән иреннәрең яраланып канга баткан. Чәчләрең күптән юылмаган, таралмаган, ул киемең турында әйтәсе юк, бүгенге көндә "Мин – кеше!" – дип әйтергә хакың да юк, син сазлык уртасында, батып барасың. Исемең – Аяз, күкләрең аяз, көннәрең, гомерең юлы кояшлы булырга тиеш иде бит. Бәхетле булып, матур хыялларны тормышка ашырып, кешеләргә изгелек кылып яшәр өчен якты дөнья бүләк иткән иде сиңа әниең, ә син әниеңә кайгылы күз яше бүләк иттең. Аяз, син үкенә белмәячәксең, дөресрәге, үкенергә вакыт та калмый бугай инде, сүнеп барасың, акыл-зиһенең тәмам томаланган, күкләрең кап-кара болытлы, кояш яктысы булмаячак та инде, өмет тә бетеп бара, яшәү ераклаша, үлем салкыннарын инде тоя да башладың. Табиблар ярдәм итә алыр микән соң, инде соң да кебек. Аяз, сиңа яшәргә дә, яшәргә иде әле, унҗиде генә яшь бит, гөл-чәчәкләрдән дә гүзәлрәк, кыя бөркетләреннән дә көчлерәк, боланнардан да җитезрәк чагың, ә син бүген ташландык йортның тынчу подвалында, үле Ренат яныннан чыгып китәргә тырышып, шуышасың, хәлең юк, җаныңны курку йомарлап алган. "Безнең урын кабердә, син дә качып котыла алмассың!" – дип Ренат синең артыңнан шуыша кебек. Куркыныч төш кенә түгел шул, бу өндә, синең өнеңдә, Аяз!

## БӘХЕТ
(Нәсер)

Ходай сине нинди язмышлы итеп яратты микән, сабыем, нәрсә көтә сине, бәхетме, бәхетсезлекме? Әйе, бу сорауга бары тик синең киләчәгең җавап бирә алачак, язмышыңның акмы, карамы булачагын, сине дөньяга тудырган әниең дә белми. Карынында чагыңда ук ул сиңа исәнлек-саулык, бәхет теләде, бишек җыры да бәхет турында. Ана кеше газиз баласын бәхетле итеп күрә, гел генә ерак киләчәккә төбәлгән күңел күзләре бары яктылык кына күрә, алда кояшлы көннәр, чәчәкләр һәм шатлык! Әллә нинди кыенлыкларга төшәсең дә, синең бөгелеп-сынып калмаячагыңа ышаначак анаң, ул бит сине матур да, батыр да итеп күрә! Син дөньяга яңа тудың, яшисе елларың, үтәсе юлларың, ашыйсы ашларың шушы дөньда, көләрсең дә, еларсың да, күрәчәгеңне күрерсең, бала!

Язларның ташкыннары бар, син алардан көч алырсың, яшәүнең бар мәгънәсе – көрәш, кеше көчле булырга тиеш, шунда гына матурлыгың күренер! Син кояштан нур ал, гөлләр үстер, йөрәгеңне яшен камчылары телгәндә дә тормышка гүзәллек кенә булып уелыр! Син мәхәббәттән яралдың, кайнар хисләрдән бар булдың, әрнеп, өзгәләнеп, авыр тулгакларын каргап тудырмады сине әниең, югыйсә, ялган мәхәббәт җимешләре дә бар бит бу дөньда, ачы, бик ачы булып өлгерә ул аз гомерле мәхәббәт җимеше, каргыш – күз яше ачы итә аны. Син сүнмәс ялкыннан яралдың, әти-әниең өчен татлыдан да татлы булып яшәрсең, сабыем! Гөнаһсыз мәхәббәт белән тибәрме йөрәгең, ялган булмасмы әйткән сүзләрең, тормышка ямь булырмы кылган эшләрең? Үзең үстергән икмәкне ашарсыңмы, адаштырмасмы сине буранлы юллар, дулкын итеп ярдан ярга бәргәләмәсме җаныңны тормыш диңгезе, нинди язмыш синдә? Әйе, мин синең өчен борчылам, сорауларыма җавап аласым килә, тик әле син яши генә

башладың, яңгыры да, бозы да,  җиле дә сиңа ят нәрсә, бер генә теләгем бар,  җилләргә түгел, давылларга да бирешмәсәң иде! Синең дусларың да, дошманнарың да күп булыр, сынаулары каты булачак, күкләр күкрәр, җирләр тетрәр син көрәшкәндә, нишләргә икәнен белерсең –җиңәргә!

Юк, мин күрәзәче түгел, киләчәгеңне белмим, бәхет елмаермы сиңа, бәхетсезлек иңнәреңнән кочармы, шуны якшы беләм, син бүген бәхетле, әйе, бик бәхетле син, әниеңнең күкрәк сөте белән тукланып яшәвең белән бәхетлесең! Әниең сине яратып җылы куеньна алган, күз карашлары синдә, йөзендә шатлык, иреннәре елмая, уйлары зур киләчәктә, синең киләчәгеңдә! Син бәхетле, сабыем, якты дөньяга тугач та ана сөтеннән мәхрүм булып калганнар азмыни?! Бала туа, ә анасы  мәңгелеккә күзләрен йома, медицина үлем алдында көчсез! Бала тапкан хатыннарның төрлесе бар, кызганычка каршы бар шул, яңа гына яши башлаган нәниен язмыш кочагына биреп, биреп түгел, ташлап киткән хатыннар турында дучар булган сабыйны ничек бәхетле диярсең, ул елаган саен каргыш яшен түгә. Чит кешеләр җылысы аның җанын җылытмый, ятимлекне җылытыр көч юк! Син бәхетле, бәләкәч, әниеңнең ак сөтен имә-имә яши башладың, сиңа карап шатланам, күзләрем яшьләнә, шул ук вакыт, әнисез сабыйлар да минем күзләремә яшь китерә. Күз яшьләре дә әллә ничә төрле була, язмышлар кебек, язмышлар бит әнә ничә төрле!

## БӘХЕТ ТУРЫНДА ҖЫР
(Нәсер)

Басу ягыннан  тракторлар гөрләгән тавыш ишетелә, язның, талгын җиле алып килә бу көчле мотор тавышын, димәк, егетләр җиң сызганып эш башлаганнар, кырда язгы чәчү бара! Күкнең зәңгәрлеге, кояшның яктылыгы, җылылыгы, таллардагы бөреләрнең сафлыгы, кошлар җыры җанга мең шатлык китерсә, хезмәт шавы  китергән шатлыкның саны юк,

ул чиксез! Бәхетнең чикләре буламы соң бүген, бүген мин килер якты көнне, иген төягән олауларны күрәм! Әнә ул келәт алларындагы өем-өем алтын бөртекләр, әнә ул шатлыгын елмаюы аша күрсәткән игенче! Көзләр уңышлы булганда игенче генә шатлык кичерми, бар да бәхетле, бар да күкрәген тутрып рәхәт сулышын ала! Бүген туфракка орлык төшә, тир тама, иртәгә дә шулай булачак, өстәлдә икмәк булмаса ничек яшәмәк кирәк, ничек юлларга асфальт түшәлсен, ничек йортлар төзелсен, ничек асыл киемнәр тегелсен дә ничек белем үрләренә күтәрелерсең, ничек шигырь язарсың! Басу ягыннан ишетелгән трактор тавышын тын гына тыңлап тордым да кулыма каләмемне алдым, матур җыр язарга иде, көе бар инде, җырның сүзләре кирәк, сүзләрен мин язарга тиешмен, ә көе, әнә, басу ягыннан ишетелә, дулкын-дулкын булып килә, колакларны, җанны иркәли, шушы илаһи музыкага аваздаш сүзләр эзлим. Табармын мин ул сүзләрне, бәхет, матур тормыш турында җыр язганда йөрәк дәрт белән, көчле итеп, ярсып тибә, чабыш аты кебек, нәкъ мәйданга ашкынган чаптар! Җыр язылачак, һавада яз исе, тургайлар тавышы булганда җырсыз калу мөмкин түгел, “Тормыш авыр, кыенлык белән яшибез!” – диләр дә ул, хак сүз булса иген үстерергә кырга чыгып булыр идеме дә, җыр кайгысы булыр иде микән?! Юк, авыр яшәмибез, басу кардан ачылды, игенче җиңен сызганды, Ходай көннәрне генә бирсен, ачлык җәфасын күрмәячәк халык, монысы инде иң мөһиме! Уҗым басуына гына кара, ямь-яшел, ничек телең барып киләчәк турында өметсез сүзләр сөйләрсең, икмәк үсә ич, монда –яшәү бар! Ризыкка язсын, бүген туфрракка төшкән орлыкны әйтәм, табыннарда бодай икмәгән кисеп бәйрәм итә -итә яшәсәк иде! Яшәрбез, Аллаһы боерса, ышаныч зур, игенче кырга чыкты! Әйе, басу ягыннан ишетелгән көйнең сүзләре язылды шикелле, җыр туды, кешелек бәхете турында бу җыр, бүгенге һәм киләчәк көн турында!

## КӨТӘРГӘМЕ СИНЕ?

(Нәсер)

Минеке бул. Күге аяз, матур көнем булып кил миңа. Ул көннең җилләре талгын гына исеп, тал-тирәкләрнең яшел ефәк чукларын җилфердәтсен, тәрәзә башларында күгәрченнәре гөрләсен, зәп-зәңгәр һаваны иңләп-буйлап, бер түбәнгә, бер югарыга атылып карлыгачлары канат каксын. Шатлыгым бул. Түтәлләргә сулар сибеп матур гөлләр үстерик. Гөлләр хуш ис бөркеп утырсын, күзләрне иркәләсен, күңелне назласын. Тормышыбыз бакчасында чәчәк атсын ул гөлләр, берсен дә өзмик, сулдырмыйк. Бергә җырлыйк, бергә көлик. Бәхет үрләренә җитәкләшеп бергә күтәрелик тә: "Мин бәхетле, бик бәхетле, бәхетем кояштай түгәрәк!" – дип бертавыштан, бар дөньяны яңгыратып кычкырыйк. Мең тапкыр кайтаваз булып яңгырар бу аваз. Минеке бул. Очрашу көннәрен көтеп талган йөрәкләргә ял бирик. Төн йокыларыбыз татлы булсын. Сагыш юшкыннары утырган күңелләребезне чайкатып түгик, яктырсын, сагышның тамчысы да калмасын. Күзләрдәге моң, яшь пәрдәсен ертып ташлыйк, дөнья яктысы, тормыш яме ачыграк күренсен. Кирәк икән – икәү бергә еларбыз, бергә суларга төшеп йөзәрбез, утларга кереп янарбыз. Давылларга каршы очарга туры килсә дә коточкыч булмас, без бит пар канат булабыз. Канатлар канга тузып, хәлсезләнеп ятып калсак та юк, бу әле "Бетте!" – дигән сүз булмас, бер-беребезнең иреннәребезгә тере су булып тамарбыз. Без яшәргә тиеш, яшәр өчен тудык, яшәр өчен очраштык, яшәр өчен яратыштык. Минеке бул. Гаҗәпләнеп тә, сокланып та карасын безгә күзләр. Ятларга бирмә мине, гомер юлымны синең белән генә үтәсем килә. Кайгысын да, шатлыгын да бергә күтәреп барыйк, таллар булып бөгелсәк тә сынмабыз, икәү булгач сынмабыз. Җиргә яңа язны без китерик, хисләр ялкыны кар-

бозларны эретсен, шатлыклы күз яшьләребез тамчылар булып тыпылдап тамсын. Минеке бул! Бу сүзләрне миңа син әйттең. Минеке бул! Минеке бул! Юк, кычкырып әйтмәдең, кычкырып әйтелми бу сүзләр, бер генә тапкыр пышылдап әйттең син, күзләреңә карап мең ишеттем шушы сүзләреңне. Мин дә сиңа күп нәрсәләр сөйләдем, күзләремнән аңлый алдың микән? "Сүзләреңнең барысы да чынмы?" – дип сорадым. Кире әйләнеп килер өчен киттеңме, көтәргәме сине? Көтәргәме?

### БӘХЕТЛЕ АНА БУЛ

(Нәсер)

Яшь хатыннар, беренче бәбиен көткән булачак аналар! Сезне күргән саен күз алларым яз яктысы белән яктыра, сезгә карап, бөре бүрттергән тирәкләрне күрәм мин, бөреле ботаклар – сезне хәтерләтә!

Күзәткәнем бар, төрле язмыштагы адәм балалары кебек, бөреләрдән дә төрле яфраклар ярала, бик матур меңләгән яфрак арасында зәгыйфьләре дә була, дөньяга беренче тапкыр күзен ачканда ук, кәкерәеп-бөкерәеп беткән була ул. Яши генә башлый, кояш аны җылы нурларына биләп алган гына була, ә аның башка яфраклар кебек җилфер-җилфер килеп шаулап яши алмаячагы күренеп тора.

Булачак ана, әле карыныңда гына кыймылдаган балаңны, дөньяга килгәч нинди язмыш көткәнен белмисең син. Син шатланып бала көтәсең. Кыз баламы, ир баламы, әле белмисең дә, ә исемнәр әзер, матур-матур киемнәре алынган, тегеп куелган. Юк, син тетрәнеп яшәмисең, туачак балаңны бәхетең итеп көтәсең. Әйе, ул һичшиксез синең, гаиләңнең бәхете булырга тиеш. Дүрт саны төгәл, бар яклап та камил бала булачак ул! Бала көткән хатын, бигрәк тә яшь кеше,

нәкъ шулай уйлый. Ә тормышта син уйлаганча гына булып чыкмый, ай-һай катлаулы ул тормыш!

Балаң туар, газаплы тулгакларың белән син сабыеңны дөньяга китерәсең. Авыр минутлар үтә, үзеңнең дә, балаңның да исән булуына шатланып күзләреңә яшь килә. Син ана булдың, әнә бәләкәчең дөньяга беренче авазын ишеттереп елап җибәрә, син елмаясың! Бала елый! Тавышы шундый матур булып ишетелә, былбыллар тавышыннан да матуррак. Бала елый-елый: "Рәхмәт, әнкәй, дөньяга тудыруың өчен. Мин яшим, ишетәсеңме, мин яшим, мин тере!" – ди ул.

Авырлы хатын белән тулышкан бөрене юкка гына чагыштыру итеп алмадым мин, менә хәзер үзең дә аңларсың. Күрәчәкне туганда ук маңгайга языла диюләре дөрестер, яши башлауның беренче сәгатьләрендә үк, авыр язмышы белән көрәшә башлаган сабыйлар бар бит, тумыштан гарип диләр аларны, кулсыз-аяксыз, сукыр һәм тагын әллә нинди кимчелекләре бар аларның. Тып-тып басып тәпи киткән нарасыйны да үзенең рәхимсез куллары белән каты итеп тотып ала аяусыз язмыш. "Гөнаһларым юк иде бит, томрап торган бала таптым. Иә, Ходай, нигә каһәрле язмышка дучар иттең минем баламны?" – дип өзгәләнгән аналар бар бу дөньяда. Аларның сүзләре, күз яшьләре йөрәк үксетә. Бәхетсез аналарны юатырдай сүзләр табалганым юк минем. Әнкәемнең чәчләре утыз яше тулганчы ук агарган иде инде, дөньядан иртәрәк китүенә дә минем язмышның авырлыгы сәбәп булгандыр. Юк, ул үзен бәхетсез, димәде, мин әчемнән генә, күзләренә мөлдерәп карап: "Әнкәй, сине бәхетле итә алмадым шул, гафу ит!" – ди идем.

Гарип баласын чит кешеләр тәрбиясенә биреп калдырган хытында ана йөрәге тибәдер дип һич уйламыйм, ана йөрәге боз белән туңган булмый, нинди генә булмасын баласы аңа газиз, кадерле. Ананың балага булган мәхәббәте ялкынлы! Ана кеше сау-сәламәт балалары белән бергә гарибен дә үз канаты астына ала, үз назын барысына да тигез өләшә.

Булачак ана, синең күңелең ничек микән, син нинди ниятттә, зәгыйфь бала туса нишләрсең, "Бу миңа кирәкми!" – диярсеңме? Юк, алай әйтмәссең! Кул-аяклары гарип булса да син аны биләүгә биләп күкрәгеңә кысарсың, ак сөтеңне имезерсең! Синең мәхәббәтең җимеше бит ул, ә җимешнең төрлесе бар, бик татлысы да, ачысы да була шул! Синең җанда, синең каныңнан яралган баланы, ни йөрәгең белән гарипләр йортына, үз кулларың белән илтәрсең, юк, бу эшне эшләмәссең син, намусың, йөрәгең кушмас, Ходайдан да куркырсың! Буй җиткән кызлар авызыннан чыккан авыр сүзләрне ишеткәнем бар, җан тетрәткеч сүзләр. Әле ул яшьлек акылы белән генә шундый акылсыз сүзләр сөйлидер, ул да ана булгач андый вөҗдансызлыкка баралмас!

Син бәби көтәсең, язгы кояш нурларына иркәләнеп агачларда бөре бүртә! Матур, бик матур бу, тиңнәре юк матурлык! Синең бәхетле ана булуыңны күрәсем килә, яшь хатын! Тормыш сиңа усал җилләр белән кагылса да, син ана булып кал, балаң янында булсың. Ул ачы язмышлы булса да, анасы янында булса, үзен бәхетсез итеп сизмәс. Синең итәгеңә ябышып янәш атлый алмаса да, канатланып яшәр. Яшәсен, ул бит яшәргә туган.

Син бала көтәсең. Алда әйтеп үткәннәрем куркыту түгел, йөрәк тавышымны ишетәсеңдер, сау-сәламәт булсын сабыең. Бала кайгысы күрмә.

## КӨТӘСЕҢ

(Нәсер)

Көтәсеңдер, барып җитә алмыйм,
Ерак юллар кирәк үтәргә.
Ризамы син, шулай, гомер буе
Яратырга, сагынып көтәргә?

Риза булсаң барып җитәрмен бер… Әйе, мине юллар сиңа илтәчәк, син шулай яратып көтсәң, юлларымда туктап калмам, очраган киртәләрне ватармын -җимерермен, барыбер барып җитеп, кулларымны кулларыңа бирермен. Юлларымда суык, карлы-бозлы яңгырлар очраса да кире борылмам, чылансам да өшемәм, юк, өшемәм, син яратып көтәсең! Бураннарда да адашып калмам мин, синең «Кил-кил!» – дип ялкынланып ярсып типкән йөрәк тавышыңны ишетә –ишетә барырмын. Дөм караңгы төннәрдә дә юлларымнан язмам мин, мине «Килер!» – дип көткән якты өмет белән яшисең лә, өмет яктысы юлларга Ай, Кояш нурлары булып түгелер, мине адашудан саклар. Синең янга кошлар булып очарга әзер мин, карлыгач булып очармын, күкләрдән күзләреңне алмый көт мине, карлыгачыңны көт. Канатларымны каерып ташлардай булып давыллары кузгалыр, канатлар яраланып канаса да куркып калмам, очармын, син бит мине сагынып көтәсең. Юк, мин бармыйча калалмыйм, ап-ак карлар яуганда да, таллар бөреләнгәндә дә, болыннар чәчәккә күмелгәч тә, сары күбәләкләр булып яфраклар очканда да көт син мине, көтәрсең, ышанам. Төн йокыларыңны бүлеп минем хакта уйлыйсың «Сагына микән, килер юлларына чыкты микән!» – дисең син. Беләсең, юллар үтүе авыр, тормыш юлы сынаулар белән тулы. Мәхәббәт илендә һәркем сират күпере үтә, без дә аны үтәчәкбез, ышанам, сынаулар сындыра алмас безне!

Көтәсең, син бүген җылы яңгыр көткән гөл! Җылы, шифалы яңгырлар булып явармын, яшеннәр булып яшьнәрмен. Юк, җаныңны телмәм яшен булып, күңел күкләреңдә балкырмын, бары балкырмын. Син бүген сандугачын өзелеп көткән бөдрә тирәк. Сандугачың булып барырмын да, өздереп-өздереп кичен-иртәләрен сайрармын.

Көтәсең! Шатлык булып барырмын, бәхет үрләренә бергәләп күтәрелербез. Көтәсең, мине күргәч синең елмаюың алсу таңнар булып атар кебек. Җаныма кояшлы иртәләр кирәк, сиңа барам!

## СӨЯРГӘ КИРӘК

(Нәсер)

Әллә нигә бер генә булса иде ул, юк шул, көн дә диярлек дару ашыйм, кан басымым күтәрелә дә башым, чигәләрем авырта башлый, йөрәк күкрәк сөяген ватып чыгардай булып суга, хәл бетә, күзләр томалана. Бавыр да үзенең кайда икәнен сиздереп кенә тора, әле чәнчә, әле сыкрый, әле шешеп үк китә. Иң туклыклы, тәмле ризыкларны читтән генә карап, иреннәрне ялмап торган чаклар күп. Чәйнәп, тәмен чыгарып ашарга тешләр дә юк бит, гомер буе авырлыкларга түзим, дип ничек кенә кысмадым мин тешләремне, уртларым шешеп тешләр коелды. Тешләрне кысып яшәдем шул, аяксыз да, кулсыз да бул, әнкәйсез дә кал, нишләмәк кирәк, тешләрне кысып уртларны канаттым! Авыртмаган бер генә җирем дә юк бугай, салкыны да тигән инде, җилнең йомшагы иссә дә арка-күкрәккә чыдап булмый, ютәлләтә башлый. Салкыны да, ялкыны да җанымда, бигрәк чыдам икән бу җан, андагы яраның күплеге! Гариплек берни дә түгел икән ул, әйе, яшьтәшләрем белән урамнарны шау-гөр китереп йөгрә-йөгрә уйнап үсмәдем, йөгермәсәм ни, утырган җиремдә курчак уйнадым. Гашыйклар төнендә, сихри ай яктысында егет белән капка төбендә тормадым мин, шулай да, гашыйк идем бит, хыялларым якты иде, минем өчен зәңгәр йолдызлар кабынды, ал таңнар атты, көннәр кояшлы булды. Минем яшьлегем яме кулъяулыкка чигелгән алсу чәчәкләрдә, әйе, мин чигә идем! Бүген бармакларым энә тоталмый, калак та тота алмыйм, кеше ярдәме белән туклanам, чәчләремне дә үзем тарый алмыйм, шулай да, гариплеккә күңел күнеккән инде, сау-сәламәт кешеләрнең үземә төбәлгән сораулы карашлары да артык борчымый. “Әйе, мин тормыштан ямь табып яшим, яшисем килеп яшим!” – дип җавап бирәм. Эшем бар ич, эшсез булсам, бәлки, авырлыкларны җиңә дә алмас идем,

тормыштагы ямьсезлекләр кояшлы күгемә кара болыт булып күтәрелер иде, эш белән янып яшәгән кеше – матурлыкны күрә белә! Гариплек һәм шуңа өстәлгән йөзләгән чир миңа гомер юлдашы булды. Арка сөякләре, куллар сызлый, күзләр чәнчешә, юк, кулдан куймыйм әле мин каләмемне! Түзсәң түз, түзмәсәң үл, ди торгандыр Ходай, түзәм, түзәм әле, үз-үзенә кул салып, бу якты дөньядан киткәннәргә үч итеп түзәм. Чиргә, кыенлыкка түзә белмичә генә үзләренә кул сала ич алар, әллә җиңмәсләр идеме, түзмиләр, тешләрен кысмыйлар! Ни күреп үләргә тиеш мин, мин чирле, мин кайгылы дипме? Юк, ике яшәү бирә алмый миңа әнкәй, бер яшәү бар, башка яшәүнең булуы мөмкин түгел, бер яшәүдә балкып яшәсен ул кеше, матур кеше булып яшәсен! Балкып яшәр өчен бу дөньяны сөяргә кирәк, ә сөю – ялкынлы, янарга, күптөрле утларда янарга кирәк!

Көн дә дару ашыйм, көн дә, “Исәнлегемне саклагыз!” – дип фәрештәләремә эндәшәм!

## КҮБРӘК АНАЛАР ЕЛЫЙ

(Нәсер)

Тупыллар мамык очыра. Ап-ак мамыкка төренгән тупылларга карыйм да ап-ак биләүгә биләп нарасыен күкрәгенә кысып, шат елмаеп торган ананы күрәм. Талгын гына искән җилгә тупыл ботаклары тирбәлә. Бала тирбәлә анда, мамыкка төренгән орлык –бала тирбәлә. Үз вакыты җиткәч һава дулкынында йөзеп орлык –бала туфрак өстенә төшә. Орлык йомшак туфракка төшеп ятса яшәү башланырга мөмкин, яңгыры, кояшы бар бит бу дөньяның! Тупыл тирәсендә яшь үсентеләр күреп шатланам мин, алар кояшлы күккә үрли, күзләрне иркәләп яшәрә! Койма буенда бала тупыллар байтак иде, буа буеннан үргә юл менә, юл буенда гына үсәләр иде алар, йә, Ходай, кемдер берәү чабып

ташлаган бит үзләрен, харап кына иткән. Юл буен ямьләп үсеннәр иде дә, үсеннәр иде, агач булса сулар һаваң да чистарак була бит! Ана тупылга карап уйлап куйдым, балаларын балта белән чапкалаганда нишләде икән, авыплар китәрлек хәлдә булгандыр, ничекләр түзде икән? Ел да бер тапкыр мамыгына төреп җиргә орлыгын сипкән ана тупылның тавышын ишетәм. Талгын җилдә яфракларын лепелдәтеп тупыл менә нәрсә ди: «Кешеләр түзә бит, аналар түзә! Без, агачлар да, кешеләр кебек, язмышлар охшаш, кичергәннәр күптөрле. Давыллар, ут-яшеннәр, карлы-бозлы яңгырлар безне тетрәндереп үксетә. Җылы кояш нурлары, назлы-ягымлы җиле безне юата, иркәли. Сабыр итүләр беркемгә дә җиңел түгел! Әйе, мин ана-тупыл, ана булу мең газаплы, без аналарның хәлең аңлый белүең өчен сиңа рәхмәт! Син миңа карыйсың да, баласын биләп күтәргән ананы күрәсең. Син кеше, кещелек дөньясы сине ныграк борчый, уйландыра. Тынычланырга урын юк шул, иминлек юк, дөньяда күз яшьләре күбрәк! Күбрәк аналар елый, без елыйбыз!»

Ак биләүдәге сабыен алдына ала да ана, җылы имчәген баланың авызына каптыра, бала тәмләп ак сөт суыра, ак сөт аңа көч бирә. Көлә, гөр -гөр килеп анасы белән сөйләшә башлый бала. Кулларга алып уйнаталар баланы, ул ана мәхәббәте, ата назы белән үсә, теле ачыла, тәпи китә. Шатлык, болар бар да шатлык! Кара кайгыга нигә урын кала соң, нигә ана йөрәген яралый ул кайгы? Әле күптән түгел генә шатланып беталмый иде ана, улы көлә башлады бит, шундый матур итеп: «Әттә, Әннә!» – диде, туп-туп итеп атлап китте, мәктәптән «5» ләр алып кайтты, ә бүген!... Бүген күктә кояш, җирдә гөлләр юк кебек, ана табут янында яшь түгә. Хезмәт иткән улы табутта кайтты, шул ерак бер илдә мәңгелеккә күзләрен йомды ул, туган җиренә кайгы булып кайтты.

Тупыллар мамык очыра, орлыклар туфракка тамыр җәяр, үсентеләргә балта чапмасыннар иде. Ана нәни улын күкрәгенә кыскан, юк, үтермәсеннәр улын, үтермәсеннәр!

## КАЙТЫЙК ӘЛЕ!

(Нәсер)

Күчтәнәчләр алып кайтырга җыенасың. Күптән түгел генә кайткан идең әле, иген шаулаган басу һавасын сулап, болын чәчәкләренең хуш исләрен иснәп, авылыңның тәмле чишмә суын эчеп килгән идең син, инде авылыңның бөдрә тирәкләре, нечкә талы, су буендагы казлар каңгылдашкан тавышлар, көтү куган иртәләр, әнкәң пешергән мич ашлары төшләреңә кереп йөдәтә башлады, кайтмыйча калалмыйсың! Кайт, авылдашым, юлларың ерак булса да авылга кайт, беләсең ич, сине әткәң-әнкәң көтә, күзләре юлда аларның, сине көтәләр, күргән төшләреннән сиңа юллар салалар. Кышкы бураннар да синең кайтыр юлларыңа киртәләр куялмасын, яуган яңгырлар, ыжгыр җилләр, гарасатлар сине туктата алмасын, очар кошлардан канатлар алып кайтыр юлга чык. Сине кочаклап алырга әнкәң колачларын җәйгәндә ничек кайтмый калырсың?! Юлга ашыгасың, әйе, сагынуларың чиксез, көткәннәрен беләсең, көткән кешең булганда сагыну тагы да көчлерәк була шул! Мин дә кайтырга җыенам, җылы яктан кошлар кайтты бит инде, авылыма кайтыр чак җитте. Шаулы шәһәрне калдырып, җәйләргә дип авылыма кайтам мин, авылны, авылдашларны күрәсем килеп кайтам. Кайтканымны әллә каян, ерактан күреп, капка төбенә чыгып әнкәм көтми шул, яңа бөреләре ачылып кына килгән ак каеннарым, мәһабәт тупылларым каршылый мине. Инде ничә ел шул ак каеннарны, яшь тирәкләрне, карт тупылларны, койма буенда үскән кычытканнарны, кыяк үләннәрне сагынып кайтам. Үзебезнең ихата турысында йөзгән ак болытлар да гел күз алдымда, әйтерсең лә алар яңгыр булып та, кар булып та яумаганнар, еракка да йөзеп китмәгәннәр, күңелдәге үткән, якты көннәр хатирәсе булып һаман да бер көе генә торалар сыман.

Авылга алып кайткан юл буенда бит зиратыбыз, әнкәм каберенең зәңгәр чардуганы әллә каян күренә, юк, машинаны туктатырга кушмыйм, бик авыр булса да зиратны үтеп китәбез, мин монда юллар коляска белән йөрерлек булгач киләм. Зират турысыннан узганда йөрәгем үкси-үкси әнкәмә эндәшәм: «Әнкәй, мин янә кайтып киләм. Дөресен әйтим, һич кенә дә шатланып, ашкынып, кайтасым килеп кайтмыйм, авыл бар да соң, анда син юк бит, мине көтеп алырга син юк!» Гүя әнкәм тавышын ишетәм, миңа җиңел булгандай тоела: «Мин булмасам да, авылга кайт, балам, ямь табарга тырыш, җәйләрең шатлыклы үтсен. Күп еллар бергә яшәгән йортыбызга кайтасың!» Әйе, яшәлгән еллар бар да хәтердә саклана андагы гүзәллек, андагылар бар да якын, кадерле. Инде кыйшая төшкән капка-коймаларда да, буявы кырылып-уңып беткән күтәрмәдә дә, ишек-тәрәзәләрдә дә, идән-түшәмнәрдә дә әнкәй төсе бар. Әнкәйдән соң ничә ачылып, ничә ябылган инде ул җимеш бакчасының капкасы, барыбер әнкәй төсен саклый ул, сукмаклар турында әйтәсе дә юк! Урам да, авыл да, киң күңелле, ачык чырайлы авылдашларым да әнкәмдәй газиз җанга, күрү белән ничек эремәссең, язмышка ачуланып, боздай катып яшәү мөмкинме?! Сине әнкәң көтә, авылдаш, бәйрәмнәрне көтеп торма, кайтырга чык, кайту ул үзе бәйрәм! Көткән кешенең бар чакта кайт берүк, шатлыклардан күңелең мөлдерәмә тулсын! Мин дә кайтам, истәлекләр белән яшәр өчен авылга кайтам!

## МӘХӘББӘТ КОШЫ ҮЛГӘН!

(Нәсер)

Мәхәббәт гөле шиңгән, көчле җил исте шул, гөлне тамыры белән йолкып алган да әллә ничә кисәккә өзгәләгән. Яфраклар яшел, яктыга сөенеп ачылган чәчәкләр кып-кызыл төсләрен җуйган. Инде беркайчан да җиргә язлар-җәйләр килмәс кебек,

мәхәббәт гөле терелмәс. Йә, Ходай, мәхәббәт чәчәксез буламыни, тормышта ямь буламы ансыз?! Карлы-бозлы яңгырлар, нигә мәхәббәт гөлләренә явасыз?! Нишләп җырсыз-моңсыз калды әле бу дөнья, тал-тирәкләр тирбәлми, кая ул мәхәббәт кошы? Аһ! Мәхәббәт кошы үлгән, ук кадалган аның йөрәгенә, канатлары каерылып кына калмаган, әллә ничә җирдән сынган. Канга баткан кошкай, кемнәр җан өрсен?! Мәхәббәт кошына кара ук аткан явызлык бар шул бу тормышта, шул явызлыкның үзенә үлем угы кадарга иде, кара канына буялсын иде ул, дөньядан югалсын иде. Ә бит моны эшләп була, явызлыктан котылыр чара бар, сафлык, дөреслек, аек акыл-явызлыктан көчлерәк! Ут сүнде, тормыш кап-караңгы булып калды, суык, тән калтыранып өши, җан туңа. Мәхәббәтнең уты сүнде, ялкынсыз калды мәхәббәт, күктәге кояш нурларыннан таралган яктылык та, җылылык та җитми бу тормышка, мәхәббәтнең ялкыны белән яшибез ич, яшәү – мәхәббәт ялкыныннан ярала! Давыл купты шул, утлар сүнмәслекмени, кузлары да сүнде, кара күмерләр генә калды. Мәхәбәтме соң бу, боз дөньсы түгелме?

Мәхәббәт кояшлы бит ул, шомырт чәчәк аткан чак кебек яп-якты, андагы наз, җылылык, шатлык беркайда да юк! Мәхәббәтнең газабы да татлы була, чөнки, ул өмет белән балкый! Әйе, бу шундый булырга тиеш, ә нигә соң ул бөгелеп төште, кеше күңеле җимерелгән кыяга әйләнде, ватылды, телгәләнде, ни булды, кем әйтер? Мәхәббәтнең көче бетте! Әйе, ул бик көчле иде, авыр сынауларны, кайгы-хәсрәтләрне җиңәр көчкә ия иде, андагы көчнең дә, матурлыкның чикләре бар икән, мәхәббәт көчен җуйды.

Сөйгәне белән әллә кайларга китеп гомер итә кеше, мәхәббәтнең сагынуны да җиңәр көче бар, туган җирен бик нык сагынса да сөйгән ярының күзләренә карап юана, ял таба! Мәхәббәт, хәтта, кабәхәт хыянәтне дә гафу итә, көчле шул ул, чикләренә килеп җиткәнче, йөрәккә кан саудырганчы мәхәббәт булып кала. Ә бүген ул көчсез, кеше упкын читендә, менә-менә тәгәрәп китәчәк, коткарырга иде, кем, нинди көч

ярдәмгә килер? Мәхәббәтнең көчсез калуы кешенең хәлен ала, шатлык та юк, өмет тә сүнәр-сүнмәс, нишләргә? Юк, кеше күзләрен мәңгелеккә йомарга теләми әле, ыңгыраша, һава җитми аңа, шулай да ул иреннәрен чәйни-чәйни үзенең тере икәнлегенә ышанырга теләп пышылдый: "Яратам! Мин яратам, яратып яшәргә хакым бар!" Ул хаклы, кабат сөяргә хакы бар! Зур дөнья булып килгән мәхәббәтнең гөле нигә шиңде соң, кошы нигә үлде? Нигә сүнде аның ялкыны, нигә көче бетте, мәңгелек түгелмени сөю? Нигә мәхәббәт күз яшьләре булып түгелә, нигә ачы нәфрәткә, рәнҗү-каргышка әйләнә? Берсе каенга сөялеп, авыр кичерешләре белән якалашып калды, икенчесе башын түбән иеп, күз яшьләрен сөртә-сөртә юлдан атлый. Хушлаштылар, аерылып китү әллә җиңел дисең, аерылып калу авыр бит!

Мәхәббәт кошы нигә үлгән, сорап кара, җавап бирә белерләрме, юк, әле юк, ерак юллар үткәч кенә, үкенүләр белән газап чиккәч бәлки җавабын табарлар. "Ашыктым, ялгыштым, түзә белмәдем!" – дияр алар, дөресе дә шулай бит! Мәхәббәтнең нәфис чәчәкләренә таң чыклары гына кунып җемелдәсен иде. Их!...

## ҖИРДӘ ЯЗ!

(Нәсер)

Ап-ак тунын ак билбау белән буып бәйләп, ак бүреген батырып киеп, ак ефәк яллы атына атланды да: «Исән-сау булыгыз, китәр юлыма чыгам, күрешкәнгә кадәр хушыгыз!» – дип кыш китеп барды. Зәһәр суыкларын, ыжгыр җил-бураннарын үзе белән алып китте. Әйе, ап-ак, ак йолдызлар булып җемелдәгән үзенең матур төсен дә алып китте кыш, юк, бөтенләе белән ак төсен, зур ак капчыгына тутырып алып китеп бетермәде ул, ак өмет итеп кешеләр күңеленә өләшеп чыкты. Өметсез ничек яшәмәк кирәк! Кыш китте, җиребезгә

көләч яз чибәркәй хуҗа булды. Яз килде дә өй кыекларына боз сөңгеләр әлеп чыкты, көмеш тамчыларын күз яше итеп, шатланып көлә-көлә елый башлады. Әйе, яз без адәм балаларына гына шатлык алып килми, үзе дә шатлана бегә, көннән-көн яктырак булып балкый барган кояш нурында күренә ул язның шатлыклары. Җир тәмам кардан ачылып бетә, челтер-челтер агып яткан гөрләвекләр җыры тына, бөре бүрттергән талларга, башка куак-агачларга кошлар оя кора, җилдә усаллык юк, талгын гына көйгә тирбәтә ул кошлар бишеген, наз белән кагыла җирдә шыткан, борын гына төрткән һәр үләнгә. Җил иңнәргә дә наз-шәлен бөркәндерә, күзләрне зур ачып, күкрәк тутрып сулыйсың да, яшәвеңә сөенеп елмаясың. Басуда пар күтәрелә, игенчеләрнең көр тавыш белән сөйләшүләре, мотор гүләүләре күңелгә шундый якын, кайнар хисләр ургылып, яңа җыр булып түгелергә генә тора. Басу тулы яшел уҗымны күрү – зур бәхет минемчә, яшел уҗым бит ул, килер көзнең уңышы, алтын башаклары дулкын булып уйнаган чиксез диңгез. Чын диңгезнең чикләре бар, ә, шатлык, бәхет диңгезенә чикләр куелмый. Икмәк үскән кырларга карап яшәү ямен ничек күрмәссең дә, ничек итеп язга шатланмассың, язларның имин килүендә бит ул килер көннәр, бәйрәмнәр!

Кыш үтә дә суык булды, уҗым ни хәлләрдә икән? Җимеш бирер агач-куакларыбыз исәнме? Кыш үтсә дә суыклары тиз генә онытылмаска да мөмкин, күңел тыныч түгел, килер көзгә кадәр кеше борчулы. Бер быел гына түгел, ел да бу шулай, шатлыклар белән янәшә борчулы уйлар да була, быелгысы үзгәрәк, дияр идем, кыш усал булды. Кыш айлары үтсә дә, чынында әле җир өсте кардан ачылып бетмәгән, якты хыялымда гына алгарак китә алдым һәм килер көннәр ямен тасвирладым, шунсыз булмый да өмет белән яшәү бу, яшәү ямен күреп куану. Әйе, кеше шулай булырга тиеш, югыйсә, нигә дөньяга туган! Кышкы, күз ачкысыз бураннар аша да чәчәкле бакчаларны, ялан-болыннарны күрәм мин. Бүген яз белән кул биреп күрешкәч бигрәк тә шатланып күңел

канатларымны кагынам, туган авылым күгенә тургай булып кайтам. Авылымны әйләндереп алган басу-кырларымны ямь-яшел итеп күрәм, егетләр җиңнәрен сызганып корыч атларын җигәләр, тупылларда яңа оялар үрелә, авылдашларым кулында тимер көрәк, һәркайсы үз бакчасында яшелчә түтәлләре казый, гөлләр чәчә. Кеше яңа язда яңача яшәргә омтыла, кешеләрдә генә түгел, тәрәзәм төбендәге гөлләремдә дә күрәм мин бүген бу матурлыкны!

## СҮЗЕМӘ ЫШАН

(Нәсер)

Язмышташым! Ачуланма бу ачык хат өчен, үзең генә булсаң иде, юк шул, язмышташ кызлар күп, сиңа гына эндәшсәм дә, барыгызга да берьюлы язам.

Кайчак Ходайга үпкәлисең: "Нигә шундый авыр язмышка дучар иттең мине?" – дип әрнеп өзгәләнәсең, яшең түгәсең. Берни дә үзгәрми, башыңны күтәрергә ашык, безнең башлар беркайчан да түбән иелергә тиеш түгел, шуны бел! Язмышың авыр, тик бу тулы бәхетсезлек түгел әле, кулсыз-аяксыз, сукыр һәм башка зәгыйфьлекләре булган кешеләрнең дә бәхетле булу мөмкинлекләре күптөрле, тормышта безнең өчен дә гүзәллекләр бар! Әйе, син күп шатлыклардан, рәхәтлектән мәхрүм булып яшисең, теләгәннең барысын да тормышка ашырып булмый, күбесе хыял дөньясында гына яши бирә, бигрәк тә үсмер, яшьлек елларында әллә нинди теләкләре була кешенең, күңел өмет итә, көтә. Син ничектер, мин үзем яшьтәш кызларым туй күлмәге кигәндә кызыгып "Ah!" итмәдем, мин ул ак күлмәкне хыялымда кидем. Хыялдан аермасын Раббым, хыял күгендәге кояш нинди якты ул! Чынбарлыкта булганга караганда кеше хыял дөньясында бәхетлерәк, хыялда хыянәт карасы юк. Сау-сәламәт кешеләр хыял дөньясында яши алмый, аларның җанын телгәләгән үзгә

нәрсәләр күп. “Ярый әле тәкъдирем болай булган!” – дип тә куясың. Сине бик тә борчыган бернәрсә бар: “Ялгызмын!” – дип зар-елап тибә йөрәгең. Яшь үләндәй үсмер чагың булды синең, бакчадагы гөлләр кебек яшьлегең чәчәк атты, күзләреңә карап “Сөям!” – диюче юк. Син бит ул сүзне көтәсең, әйе, көтәсең, “Яратам!” – дип берәү әйтсә кыш аенда да былбыллар сайрар иде кебек. Әйтмәсләр дисеңме, әйтерләр, тик үз тиңең булмаган кеше сине бәхетле итә алмый, акылыңда бул, тормыш сынавы бу, сынма, бөгелмә! “Яратам!” – дисә иде берәү, их! Син үзең дә әле берәүгә дә ул сүзне әйтмәдең, әйтә алмыйсың, “Хакым юк!” – дип уйлыйсың, әй, язмыш, күкләрең болытлы шул! Чәчәк булып үсәсең, суык җилләр синең сабагыңны кисә, кош булып очасың, сиңа каршы көчле давыл кузгала, канатларың каерыла, йөрәгеңә кан сава. Син кеше булуың белән көчле, күңелеңне генә төшермә! Язмышташым! Ышан сүземә, син ялгыз түгел, нәкъ синекедәй кичерешләр белән яшәүче ир-егет бар бу дөньяда, ул сине төшләреңдә күрә, сагына. Хыялында күкрәгенә кыса ул сине, татлы итеп иреннәреңнән үбә. Ул көн саен сиңа килә, бәхетле итәр өчен килә ул, синең сагынып көткәнеңне белеп килә. Хыялда бар да мөмкин, ләззәт кичерә белү үзе бер бәхет, андый минутлар күбрәк булсын. Ишетә бел син аны, ниләр генә пышылдамый ул егет, син дә әйт, йөрәк сүзләреңне сөйлә! Халык телендә “Пәри кияүли!” – дигән сүз йөри, син бу сүздән һич тә курыкма, син матур хыял илендә, сиңа пәри килми, пәри юк ул, акыллары зәгыйфьләр генә андый сүзгә ышана, син камил акыллы, син кайнар тойгылар белән хисләнә беләсең! Кул-аякларың хәрәкәтсез булса да син бит тере, йөрәк тавышың белән дәшеп ал үз парыңны, ул бар! Ышан! Кеше бервакытта да ялгыз булмый, аның пары бар, кайдадыр яши ул, килеп җитәр юлын гына табалмый.

Язмышташым! Кайнар кан белән яшә, эшләгән эшең юк икән – борчылма, күңел байлыгыңны энҗеләр итеп сип, кешеләр җыеп алсын, син аларны сабыр булырга, саф мәхәббәт белән сөяргә, тормыш кадерен белеп яшәргә өйрәтерсең. Сүзләремә ышан!

## ЧИШМӘ СУЫ

(Нәсер)

Гомеремдә бик күпләрнең күчтәнәчен ашадым. Каян гына килмәде ул күчтәнәч! Җир йөзендә үскән бөтен җимешләр миңа күчтәнәч булып килде. Туганнарым, дусларым, күршеләрем үзләре пешергән тәмле ризыкларны күчтәнәч итеп алдыма куйдылар. Рәхмәт, барысына да рәхмәт! Кадер-хөрмәт шатландыра, шатлыклар күп кичердем, ә бүгенгесе, бүгенге кичерешемне, шатлык кына дисәм аз булыр, бүген минем алдымда таудай бәхет! Күчтәнәчнең озак көткәнен алдым мин «Күчтәнәчне көтеп алалармыни?» – диярсез, әйе, көтмиләр, ә менә мин бу күчтәнәчне көттем, өч ел көттем. Әллә нинди ризыклар китерәләр бит, ә мин көткәнне – юк! Ниһаять, ул ризык минем алдымда. Сеңелемнең кызы, кышкы каникулда авылга кайткан иде, ярты литр банка белән су алып килгән. Туган авылның чишмә суы! Үзебезнең чишмә суы! Әнкәемнең күкрәк сөтеннән аерылгач, сабый гына чакта ук тәмен табып эчкән суым ул минем. Сагынган идем, иреннәрем кипкән чакта сагынам мин бу суны. Йөрәгем авырткан чакларда «Их, бер генә йотым чишмә суы!» – дип өзгәләнгән чаклар еш була. Ләйсән суны туңдырмыйча алып килә алган, рәхмәт! Тәмләп-тәмләп эчтем суны, рәхәтләнеп эчтем. Кышкылыкка шәһәргә килгән саен, «Күчтәнәч итеп авылым чишмәсеннән, кем генә белеп су алып килер икән?» – дип көттем. Иң тәмле, иң кадерле күчтәнәч менә шул инде, туган җиреңдә җырлый-җырлый көнгә багып, агып яткан чишмә суы! Әйе, чишмәләр җырлый ул, үз моңы, үз тавышы белән җырлый. Ул, мөгаен, тирә-ягында үскән нечкә билле тал-тирәкләрдә тирбәлеп сайраган былбыллардан отып алгандыр ул җырны. Җыры да, агышы да, тәме дә үзгә безнең чишмәнең. Иң тәмле су безнең чишмәнеке! Йотлыгып-йотлыгып су эчәм, җаным сихәтләнә бара. Беркайчан да

чирләмәм кебек тоям үземне. Юк, чирләмәм, шушы көч белән яшәрмен! Еракларда гомер иткән авылдашларым турында уйлыйм. Арада күп еллар буе кайтып та әйләнмәгәннәре бар бит, ничек түзә икән алар, чишмә суын эчмичә ничек түзәләр?

Әгәр шулай мөмкин булса, илнең төрле тарафларына китеп яшәгән авылдашларым, бигрәк тә, олы яшьтәге апа-абыйларга чишмә суыбызны күчтәнәч итеп җибәрер идем. Апалар, чиләкләрен тутырып су алып кайткан яшь кыз чакларын сагыналардыр, абыйлар да чишмә буена ат эчерергә барган булып, суга килгән кызларны күзләгән егет чакларын сагынадыр! Сагыну авыруына иң шифалы дәва бит ул чишмә суы, авылыбыз Исәнбайның чишмә суы!

## СӘЛАМ ӘЙТ

(Нәсер)

Инде әллә ничә тапкыр җиргә мең төрле чәчәген сибеп якты яз килде, юк, бу язларда син аның өчен чәчәкләр өзмәдең. Җәйләрнең татлы җиләкләрен учларыгызга җыеп алып, бер-берегезне сыйламадыгыз. Матур көзләрнең алтын яфраклары белән сибешеп уйнаганыгызга да байтак еллар үткән. Кышларның ап-ак бураннары сезнең аяк эзләрен күптән инде күмеп калдырган, эзләп тә табарлык түгел, ә менә, күңелдәге эзләр-хатирәләр исән, аларны җуяр көч юк икән, еллар үтсә дә, берни дә тонықланмаган, унҗиде яшьтәге гүзәллекне бүген дә күреп була, тик гүзәллек үзе генә түгел шул, аңа сагыш сарылган! Син дә аны онытмагансың икән лә, ул да сине сагынып яши бит, төшләренә керәсең, исләреннән чыкмаганга күрәсең! Син аны уйлыйсың икән шул, шуңа да, ул да оныта алмыйдыр, очрашкан саен, үткәннәрне искә алганда мин аның күзләрендә сагыш күрәм, сагыш пәрдәсе артына яшеренгән кеше – ул син! Гомер язы шау чәчәкле, мөгаен, беренче чәчәгең улдыр, ә аныкы –синдер. Беренче

саф, кайнар хисләр, беренче ялкын, беренче иксез-чиксез, якты хыяллар, йокысыз, айлы, йолдызлы төннәр, күбәләктәй уйнап, очып йөргән кояшлы көннәр! Әллә мәхәббәт булдымы, мәхәббәт булса нигә сезнең юллар аерылды, кем гаепле, кемнең хыянәте бүген сагыш булып үкси, җаныгызга тынгы бирми, кемне кем гафу итә алмады? Сораулар күп, юк, җавап көтеп күзләреңә бакмыйм мин, миңа болай да авыр, бик авыр, иңнәремә авыр йөк салдың, ничекләр бушатыйм шул йөкне! Хәлләрен сораштың да, сәлам әйтергә куштың "Сәлам әйт!" – дидең, юк, бу җиңел түгел, аның сине оныта алмавын беләм, шуңа да, сәламеңне әйтү, аның авыр газапларын яңарту минем күңел өчен җиңелдән булмаячак, ә сәламне тапшырырга кирәк, үземдә генә калдыра алмыйм, гөнаһ бу. "Сәлам әйт!" – диюләре бәлки сиңа да җиңел булмагандыр, йөрәктән әйтелгән сүзләр үзәкне өзә бит, онытырга теләп тә онытылмаган кешең ич ул синең, тавышыңнан аңлап тордым, дулкынландың, үксегәндәй итеп, авыр сулап әйтелде ул: "Сәлам әйт!" – дигән сүзең, инде менә ничә көн кайтавызын ишетәм: "Сәлам әйт!". Әйе, сәламеңне тапшырырмын, сәламеңне әйтеп бәлки шатландырырмын, "Ул да сагына икән!" – дип башы күкләргә тияр. Икегезнең дә үз гаиләгез бар, тормышыгыз җитеш, балалар үстерәсез, их, башка берәүне сагыну булмаса, дөнья түм-түгәрәк булыр иде! Дөньясы шулай яратылган инде, бер-берсенә гашыйк булып, яратышканнарның барысы да гомерлек парлар булалмыйлар, тормыш дулкыннары бу икәүне ике ярга кага, сез дә шулай булдыгыз. Юк, вәгъдәләр бирешмәдегез сез, нишләптер очрашулар сирәгәйде, башка берәүне пар иттегез, мәхәббәт булмаган икән лә, дип уйлап тынычланган идем, бүген, еллар үткәч сәлам әйтергә куштың да, мине сагышлы, тирән уйларга салдың. Мәхәббәт булды микәнни, шулай, гомерегез буена бер-берегезне өзелеп сагынып яшәрсезме? Сагыну газапларына ничекләр түзәрсез, бармы сездә андый көч, Ходай сабырлык бирерме!

Яшьлек үзе шундый матур, татлы газаплары белән кала шул ул җаннарда, әйе, сезнең газабыгыз татлы, ярый әле ачы түгел, күңел әрнүләре белән гомер иткәннәр дә азмыни! Сәламеңне әйтермен, мөгаен, дөнья балкып китәр, язлары үтсә дә әле гомернең шау чәчәкле җәй мизгеле, җылы да кирәк, нур да, яшәр өчен үткәннәрне дә онытмау кирәктер! Шулай уйлап үземне юатам, гомер көзләрендә дә арада сәламнәр йөреп торганда шәптер ул, әйе, шулайдыр, картлыкның килер юллары азга гына булса да бүленеп торадыр. Үткән яшьлекне сагынып елап алсаң да зыян юктыр ул, мәхәббәттән түгелгән яшьләр чык бөртекләре ич, көзге чәчәкләргә дә таң чыклары кирәк! Сәламеңне әйтермен, ярый ла, елмаюын күрсәм, уйларым мең төрле!

## ТӘРӘЗӘЛӘР

(Нәсер)

Тәрәзәләр, кояшлы тәрәзәләр! Гомер буе сезгә карап яшәдем. Зәңгәр күккә дә, ашыгып аккан болытны да, яшен яктысын да җил-давылларда бөгелгән-сыгылган агач-куакларны да сез – тәрәзәләргә карап күрдем мин. Мин утырган бүлмәдә дүрт тәрәзә: икесе көнчыгышка, икесе көньякка карый, аяз көннәрдә иртәдән кичкә кадәр кояш нурлары белән тулы була бүлмәм, җылы да, якты да. Заманча итеп, озын челтәр-пәрдә куйдырмыйм, тәрәзәнең өске өлеше генә челтәрле, чәчәкле пәрдәсе дә як-якка ачык, тәрәзә ул яктылык өчен уелган. Тәрәзә төбе саен икешәр савыт гөл. Гөлләр шау чәчәкле, гөлләремә су сибеп, тәрбияләп торсалар күңелемдә бәйрәм. Гомер буе гөлләр үсте бу тәрәзә төпләрендә, нинди генә гөлләр үстермәде әнкәй, бик матурларын яз саен авылдашларга өләште, «Бездә генә түгел, сездә дә үссен!» – диде. Кыш буе да җәй матурлыгы китмәде безнең өйдән, гөлләр чәчәк атты. Әнкәйдән соң да

гөлләр үстерәбез, тик менә кыщкылыкка күрше апаның тәрәзә төбенә күчә алар, без китәбез. Кыш чыгарга шәһәрдәге фатирыбызга китәбез шул. Менә тагын кыш якынлаша. Тәрәзәгә карап бөтерелеп очкан кар энҗеләрен күзәтәм. Әле генә бит әле, тәрәзә пыяласын көзге яңгыр тамчылары юа иде, мин аларны күз яше итеп күргән идем, инде кар ява, матур чәчәкләр, тук башаклар үсәчәк җиргә түшәлә ак кар. Тәрәзә аша күреп, таңнарның алсу төстә икәнен беләм мин, кичләрнең зәңгәр икәнен беләм. Тәрәзәдән төшкән ай яктысына каләмне манып шигырь язган төннәр бар. Тәрәзәдән күзем алмый дусларымны, якыннарымны көтәм мин, килгәннәрен күреп шатланам. Кар бөртекләрен тәрәзәдән күргән кебек, өй кыегыннан тамган язның беренче тамчыларын да башта тәрәзәдән күрәм. Димәк, минем җырларым да тәрәзә аша җаныма иңә!

Якты тәрәзәләрем – күзләремә караган әнкәм күзләре кебек. Үзәк өзелә, әнкәй күзләрендә сөйкемле яктылык та, сагыш та бар иде. Тәрәзәләр: «Тагын китәсең мени?» – дип карыйлар. Китми булмый шул! Бер тәрәзәм каршында үскән ак каен бар, мин аның бөреле чагын да, яшел, сары чагын да тәрәзәдән күрәм, әнә, нечкә генә шәрә ботаклары талгын җилгә тирбәлә. Тиздән ап-ак бәскә төренер ул, мин күрә алмам, еракта булырмын. Тәрәзә аша күңелем белән каенга эндәшәм: «Каенкай, яз җитеп син бөре бүрттергәндә кайтырмын. Исән булсак күрешербез! Синең ботакларыңа кунып сайраган кошларны тәрәзә ачып тыңлармын!!» Миңа дөнья яктысын, табигать матурлыгы күрсәткән тәрәзәләр белән саубуллашу җиңел түгел, их, алып китеп булсын иде үзләрен! Шәһәр тәрәзәләре зур булса да авыл тәрәзәләре яктырак. Гомер иткән йортның тәрәзәләре гел кояшлы кебек. Болытлы көннәрдә дә мин кояш күрәм. Күңелем тәрәзәләре дә, шушы тәрәзәләрдән якты алган, тормышка, киләчәккә юнәлгән карашларым тәрәзәләргә баккан.

## КОШЛАР КИТӘ

(Нәсер)

Күрәсезме, һавада чылбыр булып тезелгән кыр казлары канат җилпи. Юлга чыкканнар алар, китәр юлга чыкканнар, ерактагы җылы як көтә аларны. Туган җир, газиз туган оя кала, йөгерек дулкыннары белән ефәк камышлы, бөдрә таллы зәңгәр күл кала, их, кала шул!

Кыр казлары китә, суыта шул инде, көз үзенең зәһәр җилләре белән тәнгә үтә, кыр казлары китмичә калалмый. Туган җирдән китүләр булмасын иде дә соң, Ходай шулай яраткан. Әйе, китүе җиңел түгел, китүләр күз яшьле, киткән кошлар да елыйдыр, тавышлары сагышлы бит, кыр казлары да елый әнә, һава ярып ищетелгән каңгылдашулары сагышлы. "Кошкайлар, әй, сез кыр казлары, еламагыз, кайгырмагыз, китсәгез дә кайтасыз бит, дөнья яз нурына коенганда әйләнеп кайтачаксыз, парлашып, шатланышып шушында яшәрсез!" – дип кычкырасым килә, кычкырмыйм, кайтачакларын үзләре дә белә ич инде, исән-сау кайтсыннар берүк, парларын югалтмасыннар, очар канатлары каерылмасын.

Агачлар яфрак кoя, салкын җил исә, баш очымда куера барган күксел болытлар йөзә, көзге моң белән тулган күңелдә тагын әллә ниләр бар, кыр казларын күргәч әллә нишләдем, авылымнан киткән чаклар искә төште, җанның мең кылы өзелде. Әйе, китүләр бар, ничәмә төрле ул китүләр, кайтыр юлларың булса бер хәл, ә булмаса! Ана улын көтә иде, көз аенда хезмәтен тутырып кайта иде улы, әйе, кайтты солдат, цинк табутта кайтты, "Әнкәй, мин кайттым!" – дип әйтә алмады шул, күзләре мәңгелеккә йомылган иде. "Кошлар киткәндә китәм дә кошлар кайтканда кайталмыйм, көзге муллыкта әйләнеп кайтырмын!" – дигән иде улы, Аллаһы боерса, димәгәндер инде, гәүдәсе генә кайтты, исән булмагач

кайтмады кебек тоела, ана күзләрендә яшь, юк, барыбер ышанмый, улы үлмәгән кебек, Чечня җирендә җан бирер, дип тудырмады ич ул аны. Ана газиз баласын гел исән килеш күрергә тели, "Сугыш кирәкми!" – дип тибә дә соң аналар йөрәге, ишетмиләр! Сугыш харап итә егетләрне, тагын лачындай бер егетебез әнисен кайгылы итте, юк, ялгыш адымнары белән кайгыга салмады ул анасын, акылсыз сугыш гаепле! Кыр казларын күрдем дә киткәннәр турында уйладым, мәңгелеккә китүдән дә авыррагы юк, кайтмаячак бит!

Табигатьнең көзге җилләре тәнгә генә үтә икән әле ул, ананың җаны өши, кайгы туңдыра аны, балакае кайтмаячак! Быелгы көздән соң ана күңеленә җылы язлар килмәс инде, ә кыр казлары өчен язлар киләчәк, җылы, якты язлар килер. Кабер чардуганына тотынып ана очып барган кыр казларына күзләрен төбәгән, кайтырлар, кошлар, кайтыр!...

## АПРЕЛЬ ҖИЛЛӘРЕ

(Нәсер)

Апрель җилләре җылы да, назлы да булып минем җаныма иңде дә дөньяга кабат җыр булып туды. Гел шулай, апрель җиле минем йөрәгем җыры, йөрәгем тибеше булып яңгырап ишетелеп тора. Апрель җиле талгын гына искән чакта дөнья шундый яктыра, җылына, кайгы-хәсрәт калмый җирдә, рәхәт сулыш аласың, әйтерсең лә, кошлар сиңа канат алып кайталар, күңел зәңгәр күктә талпына. Күктән җирне күзәтәсең, җир шундый матур, апрель җиле уйный-уйный гөрләвекләр куа, күзләрен ачып кояшка баккан ап-ак таҗлы умырзая чәчәкләрен иркәли, үбә, нечкә билләреннән кочып тибрәтеп шаярта. Талларда бөре уяна, апрель җиле сулышыннан уяна бөреләр. Дөньяны тизрәк яшәртергә теләптер, апрель җилләре усаллашып исәргә тотына, кар сулары көчле ташкыннарга әйләнеп ярларга тула, буалар ерыла, елгалар таша. Җир чүп-

чардан тазарына, үлән шыта, басуларда бураздналар сызыла, туфракка орлык сибелә. Апрель җилләреннән башка яз килер иде микән, юк, килмәс иде, мөгаен, апрель җиле назлы булганга яз килә, яз елмая. Яктылык булып елмая яз, яшеллек булып елмая! Апрель җиле чәчләремнән сөеп исә, йомшак кына кагылып, иңнәремә челтәр шәл булып ята. Апрель җитсә шатлыкның чиге юк кебек. Ояларга кошларның кайтуын, күлләргә аккошларның төшүен бәхеткә юрыйм мин, бу хакта җырлап туялмыйм! Их, гел шулай җанга рәхәтлек биреп кенә иссен иде ул апрель җиле, юк шул, апрель җилләре минем йөрәгемә үткен хәнҗәр булып та кадалды, ярасы төзәлә торган түгел, яра һаман каный. Апрель аен җырлы, ямьле итеп кенә белә идем мин, апрельнең бер көне кайгыдан елатыр, дип, һич уйламаган идем. Умырзаялар күзләрен ачканда, кошлар иртәнге җырларын башлаганда, әнкәм мәңгелеккә йокыга талды. Апрельнең боздай салкын җиле җилегемә үтте, бәгыремне телде, мин кайгылы җырларымны җырладым. Еладым, ә барыбер җырладым, ул кайгылы иңрәүдә дә сүз яшәү турында, җилләргә генә түгел, давылларга бирешмичә яшәү турында булды. Апрель житү белән әнкәй тал, шомырт, каен ботакларын сындырып алып керә иде дә сулы савытка утыртып өстәлемә куя иде. Ботаклар яфрак яра, яшәрә. Апрель җиле керсен дип тәрәзәмне дә ача. Ак пәрдәләр җилдә җилферди, мин шатланам, кулыма каләм алам. Әнкәй миңа еламаска кушты, димәк, җырлап яшәргә! Зар елап кайгы-хәсрәтне җиңеп булмый шул, әнкәй моны белә иде. Апрель аенда әнкәйне югалттым, кайгы китергән ай бу. Кайгы булып исә апрель җиле, ә мин – җилләргә каршы барам, апрель җилләре мине әнкәй булып иркәли дә сыман. Әнкәй үзенең миңа булган бар яратуын-назын апрель җилләренә биреп калдырган ахры, мин җилләрне һаман үз итәм. Апрель җиле җиргә ләйсән тамчылары сибә, мин шул тамчыларны берәм-берәм күңелем энҗеләре итеп җырларыма тезәм. Апрель җилләре исә, мин бу җилләрне шатлык итеп тә, сагыш итеп тә җаныма кабул итәм!

## АЧЫ ҖИМЕШЛЕ ЯЗМЫШ

(Парча)

Җәй аенда Айгөлгә дә, Гөлшатка да биш яшь тулды, алар дуслар, бергә бик тату уйныйлар. Айгөл Гөлшатның керүен көтеп ала, әни булып уйныйлар ич алар, бәби булып «Үә-үә!» - дип үзләре елыйлар да, шул ук вакыт әни булып елак бәбиләрен юаталар. Өй эче гөр килеп тора, әнә, Гөлшат әнисенең яулыгына төргән дә курчагын беләгендә тирбәтә, «Әлли-бәлли, бәбкәсе, кая киткән әнкәсе!» – дип бишек җыры җырлый. Айгөл дә җырлый ул җырны, кыз аркасын терәп диванда утыра, бармаклары йомарланган хәрәкәтсез куллары ике якка сәленеп төшкән. Айгөл курчагын кулына алалмый, курчакны Гөлшат аның итәгенә салып куйган. Аякларына да басалмый ул, тумыштан гарип бу кыз, үзе шундый шат күңелле, акыллы сөйләшә, хәрефләр дә таный, саный да белә, яттан шигырьләр сөйли. Әлегә ул язмышның авыр, бәхетсез икәнен белми, сабый күңеле күгендә кояшы бар, әле дөньясы якты, кайгы болытлары каплап алмаган аның күкләрен, язмышын каргап яшь түкми, ак халатлы апа-абыйларга ышана ул, аякларына басып йөгреп йөрер әле!

Әлли-бәлли, әлли-бәлли,
Кыз йоклата курчагын.
Хәтеремдә, бар иде лә,
Курчак уйнаган чагым!
Зәңгәр күзен йомды курчак,
Тиздән йоклап китәчәк,
Курчак йоклаткан арада,
Алтын еллар булып кызның
Бала чагы үтәчәк!

Әйе, сау-сәламәт, курчактай матур булсаң да, карап торуга кызганыч бер гарип булсаң да сабый чак үткәннәрдә торып кала. Гомернең чәчәкле язы башлана, ләйсән яңгырлары алып

килә ул язны, яшел тирәктә сайрашкан былбыллар алып килә. Гарипләр күңелендә дә зәңгәр күл бар, зәңгәр күлгә аккошлар килми каламы, киләләр ул пар аккошлар, кайнар хисләр белән мөлдерәмә тулы була күңелләр. Гарип кыз да гашыйк була, кемгә булсын, сау-сәламәт егеткә, шул егетне уйлап төн йокысын йокламый ул, йолдызларга, түгәрәк айга серен сөйли. И хыялларның матурлыгы, шул хыялларның барысы да чынга ашса, бу тормышта бер генә тамчы да ямьсезлек булмас иде! Кыз ярата да бит, ничек итеп ул егетне үзенә каратмак кирәк, бу бит акылсыз кеше уе булыр иде, гарип кызга нишләп карасын, ул бит сау-сәламәт егет! Әйе, карый ул, карашлары очрашкан чаклар бар, күрми ич ул, кызның утта янганын белми, болай гына карый, бәлки әле: «Мескен-бичара!» – ди торгандыр. Гарип егетнең дә хәле шул чама, ул да коляскасы белән урамга чыгып утыра да, чыр-чу килеп көлешкән, сөйләшкән үсмер кызларны күзәтә. «Их, берсе матур инде, акыллы да күренә, исәнләшеп үтә һәрчак!» – дип тынычсызлана егет. Ничек итеп күзләренә карап йөрәгеңне ачмак кирәк «Кит, гарип бит син!» – дип әйтәчәк! Мәхәббәт гарипләргә дә күкләр күкрәтеп, җирләр тетрәтеп килә. Әй, гашыйклар күз яше, иртәнге чыкка әйләнеп гөлләргә кунасыз ла! Гарипләрнең хәле җиңел түгел, кеше ярдәменә мохтаҗ ул, кашык тотып ашатырга да, савытка утыртырга да кеше ярдәме кирәк, ярый ла, авыр сүзләр әйтми генә ярдәм күрсәтсәләр, тешләреңне кысып түзгәнеңне иң якын кешеләрең дә аңлап бетерми бит әле, сүзгә килеп бетәсең. Берәүгә гашыйк булып, яратып яшәвеңне белсәләр, көт тә тор, йөрәгеңне канатканчы ялап куярлар, җаныңны әрнетерләр. Гарипләр мәхәббәт, гаилә кору турында уйлап та карарга тиеш түгелләр, аларга хас нәрсә түгел бу. Гарип булгансың, гөнаһсыз булып утыр, әти-әниеңнең, туганнарыңның таза-исән булуын телә. Син теге дөньяда фәрештә булачаксың! Әй, юк, күп гарипләр моның белән килешеп бетми, ул да якты дөньяга кабат тумаячак, нигә әле сөймәскә-сөелмәскә?! Шатланып, бәхетле булып яшисе килә һәркемнең, гарипнең дә үбешәсе килә!

Чәчәкләр арасында да зәгыйфь чәчәкләр үсә, алар да жылы кояшка үрелә, аларны да йомшак җилләр кочып тибрәтә, дөнья шулай яратылган, һәркемнең һәрнәрсәдә үз өлеше бар. Гариплләр арбасында бер кыз утыра, аның исеме Наилә. Кызның ефәк кебек чәчләренә кагыл әле, егет, коңгырт күзләренә кара, бит алмаларын гына түгел, син аның иреннәреннән үп, балланып пешкән җиләк бит! Коляскасында этеп чәчәкле болыннарга, тургайлы кырларга, алып чык, су буена алып бар, ак төнбоек чәчәгенең дулкыннарда бәвелүен үз күзләре белән күреп шатлансын, бәлки күргәне дә бардыр, тик синең белән, чынбарлыкта гизмәде бит әле ул матур табигать илен, бар да хыялында гына булганы бар. «Яратам, мин сине, бик бәхетле итәчәкмен!» – дип әйт син аңа, әйе-әйе, шулай дип әйт гарип Наиләгә. Айратның дә бәхетле буласы килә, чибәр кыз, бар егет янына, ул синнән наз көтә, иреннәреңне бер суырсын әле, жәлмени! Хисләренең ташып торган бер мәле, бәхетле булсын әле, ак беләкләрең белән иңнәреннән кочып иркәлә. Тукта! Туктагыз, бармагыз гарипләр янына, якын да барасы булмагыз, рәнжү-каргыш алмагыз гарипләрдән, алар каргышы төшә, кара күмергә калырсыз. Ата-анасына таудай кайгы булып туган инде ул, җанындагы яралар төзәлә торган түгел, синең ялган хисләрең белән дә өзгәләнмәсен. Яратмыйсың ич, нигә алдарга, нигә аның йөрәген уенчык итеп уйнарга?! Ышанмаячак ул сиңа, пышылдап әйткән сүзләрең белән ләззәтләнсә дә бу аз гомерле булыр. «Юк-юк, бу ярату түгел, бары жәлләү генә!» – дип үз акылында калырга тырышыр Наилә дә, Айрат та. Гарип гарип белән генә бәхетле була ала, бу хакта белә ич алар, шуңа да, үз тиңнәрен эзлиләр. Лилия коляскасы белән көзге каршына килеп туктады да кулларын көч-хәл белән күтәреп чәчен көйләде, күз кабакларын буяды, иренен кызартты. Күрше Фәнис абыйсы фотога төшерәчәк. Лилия фоторәсемен язмышташы Фәриткә юллаячак. Хат язышалар алар, егет үзенең сурәтен җибәргән, әнә ул нинди матур, мыеклы, шомырттай кара күзләре көлеп тора!

Гариплəр дə хис-тойгылар белəн яши, язмышлары ачы җимешле дип йөз чытып, уфтанып, зар елап кына утырмыйлар, яшəүнең татлы чакларын да насыйп итə аларга Ходай. Гарип кеше ут йотып үткəрə көннəрен дə, төннəрен дə юк, язмышын каргамый, тормыштан чеметем-чеметем булса да, барын да ала бит ул. Акылсыз аны кимсетсə дə акыллы – хөрмəт итə! Нишлəп əле гариплегеннəн кимсенеп өйдə утырсын Фəридə, тышта күбəлəк кар ява, чыксын əле ул, чыксын, кар-күбəлəклəр килеп кунсын чəчлəренə, аклыкта шатлык бар!

## ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ

(Нəсер)

Яңа гасыр! Беренче көн! Бүген, бер төн, бер көн эчендə йөзлəгəн бала якты дөньяга килгəндер, бəлки əле җир йөзендə туучылар саны йөзлəр белəн генə түгел, меңнəр белəн санарлыктыр. Булсын гына, тусыннар, туу – чиксез шатлык бит ул! Яңа гасыр белəн бергə, бер үк минутларда туган сабыйларга бəхетле, озын гомер телим, ризыклары киң булсын аларның! Шуны белергə иде, яңа гына туган меңлəгəн баланың берсе генə булса да йөз ел буе яшəргə туды микəн? Их, бу сорауга беркем дə дөрес җавап бирəлми шул, ерак килəчəк кенə моны белəчəк! Шулай да, минем күңелгə ул кеше, йөздə əллə ничə яшькə җиткəнче яшəячəк кеше бүген тугандыр, ап-ак билəүдə тыныч йокысын йоклап ятадыр кебек. Шул сабыйны күрəсем килə, ул бит миннəн соң бик озак яшəячəк, йөз ел эчендə бик күпне күрəчəк. Минем аңа əйтер сүзлəрем бар, ул бик зур үзгəрешлəр чорында яшəр, рəхəт тормыш алда, безнең көннəр турында сөйлəсен иде ул үзенең оныкларының оныкларына. Əйе, ул сөйлəр, бездəн соң нилəр генə булмас бу дөньяда, тормышта нилəр генə үзгəрмəс! Йөз елдан соң бəлки əле эчүнең дə, тартуның да, наркотикның да

ни икәнен белмәсләр, чир, дару дигән нәрсәнең дә үзен күреп түгел, тарих сөйләүдән генә белерләр. Әйе, киләчәк гасыр кешеләре безнең көннәрне чит-ят тормыш, сәер яшәү итеп күзаллар, бәлки әле безне мескеннәр итеп күрерләр, надан, акылсыз, диярләр, бәлки хаклы да булырлар, яшәүнең кадерен белеп яши белмибез ич. Бүген туган, йөзъяшәр кеше белән, егерме, утыз ел булса да бер һаваны сулап, күбесен уртак кичереп яшәрбез әле без, күп нәрсәнең тере шаһиты булачак ул. Минем күрәсем килгәннәрне ул күрәчәк, юк, бу көнләшеп әйтү түгел, шулай да, үләсе килмәүдән әйтелә. Чабаталы заман белән бүгенге заманның аермасы җир белән күк аермасы булган кебек, бүгенге көн белән йөз елдан соң килгән көннең аермасы да, ай-һай зур булачак! Табигать үз көчендә калачак, ә кеше акылы – зур көчкә ия булыр! Әйе, табигатьне үзгәртә алмаслар, ап-ак булып шулай карлар явар, яңгырлар кояр, бер давыллы булып, бер талгын, наз белән җиле исәр, кошлары да бер килер дә, бер китәр, гөлләр дә чәчәк атар, яфрак кояр, тузаны күтәрелер, шаулап сулары агар, туарлар, үләрләр. Кояш кояш булып калыр, Ай да, йолдызлар да үзгәрмәс, Җир әйләнер, тетрәп алыр, кеше җимерек астында калмас, димим, табигатькә каршы торыр көче бәлки ул вакытта да булмас, кеше бары кешелек дөньясындагы хаталарын гына төзәтәчәк, аң, белем үсеш алгач тормышта матурлыктан башка нәрсәнең булуы мөмкин түгел! Бүген, яңа гасырда туган бала йөздә унбиш яшенә җиткәч үзе туган-үскән заманын хәтерендә саклап, яңа туган буын яшьләренә барын да сөйләр, гыйбрәт итеп сөйләр. Йөз елдан соң да эчкечеләр, наркоманнар, ирекле мәхәббәт коллары булмас бит, чүплекләрдә яңа туган балалар әрнеп еламас. Ятимлек салкынында өшемәсләр сабыйлар, гаилә учаклары сүнмәс! Әйе-әйе, йөрәкләрне телгәләгән хыянәт тә булмас ул вакытта, хисләр мәңгелек ялкында булыр. Бер кушылган юллар аерылмас, юк-юк, канатлар каерылып канамас! Явызлыклар кылмас бәндә, төрмәләр бетәр, күз яшьләре кибәр. Үлем генә китерер ул күз

яшьләрен, үлем ул чакта да ачы булыр. Җыр – һәрвакыт булачак, сөю булгач җырсыз булалармыни!

Яңа гасыр! Бәгенче көн үтеп бара, яңа туган балалар арасында кем генә юктыр, үсәрләр дә белемгә ия булып алырлар, үзгәртерләр тормышны, яхшыга үзгәртерләр. Яңа гасыр елан елында туса да күңел һич хәвефләнми, елан да җан иясе, җирдә еланнар да шуышсын, җир – тереклек өчен! Кыш та, елан тәне дә суык була, Яңа гасыр, яңа ел туган төн шундый җылы булды, көне дә язны хәтерләтә, тамчы тама. Шигем юк, гасырдан да озынрак гомерле булып яшәячәк кеше тугандыр, әле ул анасының ак сөте белән тукланадыр. Әйе-әйе, ул шулай яшәргә көч җыя! "Ак сөтең, җылың, нызың, гомумән, бу яшәү өчен меӊ рәхмәт сиңа, анам!" – диячәк ул йөз елдан соң да!

## АПРЕЛЬ ҺӘМ МИН

(Нәсер)

Бүгенге көннең матурлыгы. Сокланып күземне тидермәсәм генә ярар иде, дип курыкып куям. Тышта язның иң шаулы, иң назлы ае, тамчылары, җырчы гөрләвекләре, көчле ташкыннары булган апрель. Көн яктысын өй эченә үткәреп тәрәзәгә капланган да апрель, миңа эндәшә. "Чык", – ди. "Иртәрәк бит әле, минем өчен иртәрәк, кар-бозларың салкыны куркыта мине!" – дим. Кайнар хисләремне түксәм әллә, күз ачып йомганчы кар-бозлар эреп бетәр иде дә бит, бу мөмкимне соң, мөмкин түгел ич. Матурлыгыңны күреп талпынган күңелемне чак-чак тыеп торам. Кош булып очып китәрмен кебек. Тыныч кына, эшләремне эшлим әле, үртәмә син минем күңелемне, ярсытма. Юк, китми апрель тәрәзә яныннан. "Кырык эшең кырык якта калсын, чык!" – ди ул. "Назлы җилләрем керфекләреңә кагылып үтсен. Иркәлисем килә үзеңне. Моң-сагышларын түгеп, күңелеңә өр-яңа шатлык

җырлары саласым килә. Бөре бүрттергән тирәкләргә кунып сайраучы беренче кошларымның тавышларын гына ишеттең, үзләрен күрмәдең дә ич әле. Сыерчыклар быел соңлый, дип моңсуланып җырлар җырладың, алар өчен борчылдың. Чык та туйганчы кара үзләренә. Кардан ачылып килгән киң кырлар өстенә күз төшәр. Тиздән анда тәүге буразналар сызылыр, тургайлар җырына, хезмәт сөйгән авылдаш егетләреңнең көр тавышы килеп кушылыр. Таңнарны хезмәт шавы белән каршылар алар. Хәер, инде алар күптән кырда. Талгын җилдә тирбәлеп ишетелгән тракторлар, машиналар гөрелтесенә колак сал. Урамда шау-гөр килеп, яз килгәнгә шатланып уйнап йөргән балаларны күрүгә, алтын елларыңа кайтып әйләнерсең. Күзләрне чагылдырып балкыган кояш нурларына урармын үзеңне. Саф һавамны күкрәгеңә тутырасым, кар сулары эчеп үскән тәүге гүзәлләрем умырзаяларны сиңа бүләк итәсем килә минем, чык кына!” – ди апрель, шатлыклы тойгыларыңның иге-чиге булмаячак.

Түзмәдем, чыктым. Апрельне мин генә шулай өзелеп сагынганмындыр дигән идем, ул да сагынган икән, чыгуым булды, ул мине кочаклап алды. Күп көннәрдән соң янә табигать кочагында иркәләнүе нинди рәхәт. Дөнья тулып язгы моңнар агыла. Ямьле яз белән, беренче чәчәкләр белән, дуслар!

## АВЫЛ

(Нәсер)

Минем авылым яңа түгел, ямаулары аның бик күп. Балкып торган төзек йортлар берничә генә, алары да гади генә, сырлап-бизәкләп эшләнмәгән. Бар бит ул авылларда йортлар, төзиләр соң, уенчык кебек матурлар! Бездә алай түгел. Авылны яңартырга иде, яңартыр өчен яшьләр кирәк, яшьләр – шәһәрдә. Авыл яңармый, яшәрә генә, җәй айларында минем

авылым ямь-яшел, әллә ничә төрле агачы шаулап яфрак яра!.. Күпме генә яшел булмасын, бу авылның яшьлеге түгел. Башка авылларга яшьлек кире кайта бит, минем авылыма кайтмас микәнни яшьлек?

Зур булган авыл, 4 бригадага бүленеп эшләгән авыл халкы. Китмәгәннәр. Китүләр сөргенгә җибәрүдән башланган. Сугышка да улларын озаткан авыл. Әйе, дөньядан китүләр дә, китү инде, ачлыгы да, чире дә халыкны кырган, авылымның ике зур зираты бар. Кемнәр туып-үсмәгән дә, кемнәр генә яшәмәгән! Авыл күпне күргән, ермалак кына булып су агып яткан елга ярларыннан тирән аның яралары, авыл түзә, ыңгыраша-ыңгыраша әлегә түзә.

Бездә гади халык яши, үтә дә чаялар юк. Бар да тигез хокукта. Мал карыйлар, иген үстерәләр, бәйрәмнәр, туйлар ясыйлар. Туйлар! Әйе, туй итә дә яшьләр, читкә китеп оя ныгыта. Туып-үскән авылга кунакка гына кайталар яшьләр, кайтмаганнары да бар. Авылда эш күп, яңгырлар яуганда юлны аркылы чыгар хәл юк, пычрак, баткак, төннәрен караңгы, баганаларда ут юк, заманча клубы, китапханәсе юк. Юк шул, юк, җиң сызганып эшләрдәй белемле яшьләре адашып чит җирләрдә йөргәнгә авылда юллар начар, клуб, китапханә эшләми. Клуб ачылса да анда магнитофон тасмасында чит ил музыкасы, әллә кемнәр ярылырдай булып акыралар. Кая гармунчыларыбыз? Сабантуйларда гармун тавышы ишетәбез әле, гармун уйната белгән авылдашлар сабантуйга кайтып күңелне күтәреп китәләр.

И, авыл! Бугенге көнеңне күреп үткәннәрне сагына күңел. Егетләрнең гармун тотмаганы сирәк иде. Ямьле иде безнең кичләр. Мәхәббәт тә саф иде. Сафлыкны тере чәчәк итеп күрә беләләр иде элек авыл кызлары. Хәзерге кызлардан аракы исе килә. Егетләр белән бергә утырып эчәләр, тарталар, яшьлекнең чәчәкле тугаен ничек телиләр шулай пычраталар. Авылны ямьсезли генә бу яшьләр, алар яңартучы түгел. Укып һөнәр алганнары, әйтәм бит, кунакка гына кайта. Авылда яшәүчеләрнең күбесе картлар. Олыгайганнар инде,

авыртыналар-сызланалар, авыл белән бергә картайганнар. Киләчәктә кем яшәр, әлеге санаулы гына яшь гаиләдәге балалар да, кошлар артыннан китсә, авыл бетә дигән сүз. Бетә, җан бирә, бу бит коточкыч, авылны тергезергә иде, бетмәсен иде ул! Авыл бетсә, анда яшәүчеләрнең исемнәре дә онытылачак! Әлегә авылның бөдрә талларына кунып сайрарга дип яз саен сандугачлар килә, иген үскән кырларны күреп шатланыр өчен, күккә тургай күтәрелә, яланында җиләге пешә, ә авылның газиз кыз-уллары чит җирләрнең суын эчә! Авыл күз яшьләре белән елый кебек, аларның бала чагын хәтерли бит ул. Малайлар тал чыбыгын ат итеп чаптылар да кешнәп торган йөгрек тайларны йөгәнләргә теләмәделәр, киттеләр.

Кызлар консерваны чиләк итеп чишмәгә суга киләләр иде. Авыл чишмәсе аларны сагына, кызларның күбесе читтә. Чит төбәккә килен булып төштеләр, авыл егетләренә чыкканнары да читкә каерылды, төйнәлделәр дә, чыгып киттеләр. Авылны гаепләргә берәүнең дә хакы юк, без, кешеләр, үзебез гаепле!

Качаклар авылларга кайтып урнаша, безнең авылга да килсеннәр иде. Чит кешеләр булса да яшәтсен иде, гомерен озайтсын иде авылның.

Авылкаем, мин дә сиңа җәйләр өчен генә кайтам. Яшел куакларында сайрап яшәгән кош кына мин. Язмышны үзгәртеп булмый, үзем китмәдем, тормыш җитәкләде. Китәр юлларыма чыккач каерылып еладым, китми калып булмады. Үзе теләп ничек китә икән кеше, ул да елый микән? «Авылда ямь юк!» – диләр, каян булсын соң ул ямь, авыл уртасындагы буаны да корыттылар бит! Нинди ямьле иде буа буе, тал-тирәк әйләнеп үскән, суында каз-үрдәкләр чумып уйный, көн буена бала-чагалар да шунда чыркылдашып яталар. Кул көче белән буган чакта су шундый күп булып жыела иде, карап торуга нәкъ түгәрәк күл инде менә, хәзерге техника өчен ярты сәгатьлек эш ул, юк, эшләнми. Кешеләр гаепле, әй, кешеләр!...

Авылым, син миңа бик кадерле. Синдә минем күп елларым, кайгыларым, шатлыкларым. Рәхмәт, барысы өчен дә. Таңнарда әтәчләр кычкырсын иде әле, иске булсаң да яшә иде, авылым. Сагынып кайтырга язсын әле, сөенеп җырлар язарга язсын. Әнкәемнең каберен күрдем, синең дә кабереңне күрергә язмасын, авыл!

## АК ЧУК, КАРА ЧУК

(Нәсер)

Гөрле качышлы уйнарга ярата идек. Күпләр идек без, бер урам бала-чага. Бер уйнаган әле дә хәтеремдә. Матур, кояшлы көзге көн. Әйтерсең лә, безнең шау-шу белән генә тулган бу дөнья.

> "Ак чук, кара чук,
> Монда торма, бар чык!"

"Гөрләргә миңа чыкты. Барыгыз, бар, качыгыз! – дидең син, – Ә, дигәнче эзләп табачакмын үзегезне!" "Шулаймы, ә, дигәнче, – дисеңме, – Менә качам, караңгы төшкәнче эзләп тә табалмассың!" – шулай дидем мин. "Минме тапмыйм?" – дидең син, – табармын күреп торырсың, бар кач, кач. Бер, ике, өч, төрлебез төрле якка сибелдек. Ә, дигәнче имеш, кая качарга соң? Шулчак, күршебез, агроном Гали абыйны очрадым. Ул кара айгырын җигеп басуга чыгып бара икән. "Гали абый, мине дә үзең белән ал әле!" – дидем мин. Синең белән шактый ара бар иде ишетмәгәнсең икән әле, ярый. "Басуны күрәсең киләме?" – әйдә, диде Гали абый, үз яныннан тарантастан урын биреп. Берегез дә шәйләмәдегез мине. "Инде эзлә!" – дидем мин эчемнән генә. Куанып куйдым, үземчә менә ничек кызык иттем бит сезне! Урамның яшел үләненә йөзең белән капланган килеш, кычкырып санаганың гына ишетелде, "Сиксән алты, сиксән җиде, сиксән сигез!" Озак эзләгәнсез мине. Өйдә юкмы, дип әнкәемнән дә

сорагансыз. Болай ерак качып китүем сезгә, бигрәк тә сиңа ошамады. “Берлекчәгә генә каласың, бу кыланышыңнан соң сине уенга катнаштырмасак та була!” – диден икенче көнне. Еллар үтте, инде зурлар без. Зурлар ләкин, әле булса гөрле качышлы уйныйбыз түгелме? Әйе, уйныйбыз. Тик моны уен, дип буламы? Бу юлы син качтың, күрше кызың сине эзли. Юк, качмадың син, киттең. Саубуллашып киттең. Хәерле юл теләп, кул болгап калган идем. “Китәм!” – дигән сүзең үзәгемне өзде, син минем күңелемдәниләр барын белми идең шул. “Белмәсен әйдә, китәр дә, онытырмын!” – дигән идем. Юк, башка берәүне күңелем якын итә алмады.

Көзләр җитсә сагышларым арта, сагынуларым әйтерсең лә көзге яфрак, сап-сары. Йөрәгемдә әйтелмәгән сөюем ялкыннары. Кыш салкыннары куркытмый мине, учларыма кар бөртекләре килеп куна да, “Ак килеш, саф килеш сакла хисләреңне, сакла, сакла, сакла!” – диләр кебек. Язгы гөлләр, “Юк, бу бәхетсез мәхәббәт түгел, бу чын ярату. Чын ярату гына шулай газаплы була, газапларыңа түз, түз син, көткәнең килер, һичшиксез килер!” – диләр кебек. Җәйге кичләрнең йолдызлары миңа сине эзләшәләр. Җем-җем итеп күкне генә түгел, минем күңелемне дә балкыталар алар. “Өметләрең сүнмәсен. Табылыр ул, табылыр!” – диләр. Кайда икәнеңне белсәм, яннарыңа барыр идем микән? Юк, бармас идем, кыз бала горурлыгы белән матур. Үзең кил иде, үзең, үзең, үзең.

## АП-АК КАРЛАР ЯУГАНДА

(Нәсер)

Күбәләкләп кар яуганда рәхәт тойгыларга бирелеп, бар мәшәкатьләремне оныта язып, тынып кала идем.

Шундый тынлык, йөрәгемнең леп-леп тибүе, күңел кылларымның сызылып кына, әле бер композитор да ишетмәгән шатлыклы көй чыңлатуы, бар дөньяга ишетелеп торадыр кебек

иде. Шундый сихри минутлар кире әйләнеп килсен иде тизрәк. Сагынам мин ул минутларны, сагынам. Минутлар гына булса да, алар җан өчен бер озын гомер кадәр булып тоела иде. Иңнәреңнән бәхет кочып алган мәл бит ул рәхәт минутлар! Кар ява! Ак бураннар арасында адашып каласым килми. Күңел адашмасын, тулпарымның җилләрдә җилфердәгән ефәк ялына нык ябышам, берүк читкә тайпылмасын, юлын дәвам итсен, барыр җиремә илтеп җиткерсен. Ап-ак карларга төренеп тынычланып калалмыйм, тәрәзәм каршында күпме кар бөртекләре очышса – уйларым шулкадәр. Кар ява! Быел да кар күп. Кырларда икмәк уңар, алмагачлар алмалы, аланнар җиләкле, болыннар чәчәкле булыр. Яз җырын җырлап агачак гөрләвекләр, шарлавыклар бит бу кар бөртекләре! Менә шушы матурлык хыкында гына уйлыйсы килә дә бит... Кар аклыгы, кар яктысы белән генә тулышмаган күңел, бүген мин һава тулып яуган карны күз яшьләренә охшатам. Кар өстендә кан күрәм, атышкан, ыңгырашкан тавышлар ишетәм. Җир йөзе фаҗигаләр белән тулы. Җанны тетрәткән хәбәрләр күңелгә борчу салды, төн йокысыз калдырды. Кар ява! Тәрәзә пыяласына сыланган карлардан күңел гөлләренә салкынлык бәрелә. Җир шарын әйләнеп, уч төбедәй җирне дә калдырмыйча явадыр кебек бу карлар.

Чынлап та шулай булсын иде, әйе, мин аның шулай икәненә ышанам да. Дөнья тулып ап-ак кар ява. Һава дулкынында тирбәлгән ак карларга: “Явыгыз, карлар, явыгыз, аклык сафлык кирәк, бик кирәк дөньяга. Тормышны явызлык түгел, изге эшләр генә бизи ала. Кеше күңелен кердән чистартып явыгыз, карлар!” – дип кычкырасым килә. Мәңгелеккә кар таулары астында күмеп калдырасы килгән нәрсәләр күп, алар бүгенге ата-ана назыннан мәхрүм калган сабыйларның елау тавышы, явыз күңеллеләрнең пулясыннан ауган яралының сызлануы, авыр югалту газапларына дучар булганнарның ыңгырашуы, хыянәт телгәләгән йөрәктән тамган кан, төзәтеп булмаган ялгышлар, үкенүләр! Юк, тыныч кына күзәтеп булмый яуган карларны. Дөнья хәлләре төрлесен уйлата. Кар бөртекләре уйларымны белми, алар үзләренең аллы-гөлле чәчәкләр булып җилләрдә тибрәләчәген генә белә бугай.

## АТЛАР КЕШНИ

(Нәсер)

Җәйге кич. Искән җил тынып калган. Кояш иртәгәгә кадәр авыл белән саубуллашып офыкка кереп югалды. Хәерле төн килүен теләп, кояшны озатып калдым. Әле якты, болын ягына күз ташлыйм. Атлар кешнәве шундый матур булып ишетелә, җыр тыңлагандай күңел иркәләнә. Атлар үзләре генә түгел, яннарында болын буйлап чабып уйнаган бөдрә койрыклы колыннары да бар. Колынкайлар чабып киткәч, «Ерак китмәгез!» – диләрдер, бияләр әледән-әле кешнәп тавыш бирәләр. Көтүче егетнең ара-тирә сызгырып чыбыркы шартлатканы ишетелеп куя. Авыл җиренең бер матурлыгы бит бу! Атларны бик яратам, яратып рәсемнәрен төшерәм. Келдер-келдер арба тавышы да, кар өстен чыжлатып үткән чана тавышы да якын миңа. Ат исен үз итүемне дә яшермим, безнең ихатада күп еллар ат булды. Әткәй күрше авылга ат җигеп эшкә йөрде, шунлыктан ат миңа ят түгел. Күп еллар Жучок кушаматлы атны җикте, бик акыллы булды малкай, аяк астында чүпләнеп йөргән тавык-чебешләрнең берсенә генә дә тоягын тидермәде.

Берничә ел элек атларга игътибар кимеде, техника заманы кеше акылын зәгыйфьләп куяр чиккә җитте. «Атларны бетерәләр, алар зоопаркларда гына калачак икән!» – дигән сүзләрне ишетеп йөрәк "жу" итеп куйды. Янәсе, ат белән әллә ни эшләп булмый, техника барын да аткарыр! Ракеталар кешеләрне галәм киңлегенә күтәрде, ат ат инде, җирдәге тереклек! Юк, болай әйтү гөнаһ булыр, атлар да кеше күргәнне күрә, күргәннәре санаплар бетергесез. Атлар сука сөрде, җир тырматты, буразна ярды, сугыш яланында яраланды, үлеп калды.

Атлар урман чыгарды, ачлыктан кипте. Тыныч таңнар атып тормыш бер җайга салынгач атлар да чабышып уйный

башладылар. Атлар кешегә хезмәт итә, авыр йөк тарта. Атлардан башка сабантуйлар булмый, сабантуйлар атсыз калырмы? Шушы сорау йөрәкне телгәләде. Утарларда атлар саны кимеп калгач авыл кешеләре авыр сулап уйга калды. Юк, атларны зоопаркларда тимер читлек эчләренә ябарга ярамый, ат ерткыч түгел бит!

Болыннарда атлар кешни, миңа аларны ишетүе рәхәт. Колхоз утарларында гына түгел, хуҗалыкларда да атлар күп. Бер генә дә түгел, берничә баш ат асраган хуҗалыклар бар авылда. Бу, әлбәттә, шатлык. Халык шулай муллык белән яшәсен. Машинасы да, аты да булсын, булсын гына! Атларны бетерәләр дигән сүз ярый әле сабын күбеге генә булды. Ямь-яшел тугайларда ефәк ялларын җилфердәтеп атлар чаба. Менә бит ул матурлык! Хәтерлим, 4–5 яшьлек чагымда минем дә атка атланганым бар. Әнкәйнең энесе Рафаэль Шәкерт абый үз янына ат өстенә алды да мине, урамны әйләнеп килдек. Ат өстендә кеше үзен канатлы кош итеп тоя икән ул, миндә дә канатлар бар иде. Тагын бер нәрсә турында әйтми калу һич мөмкин түгел. Атларга атланып чапкан егетләргә кызлар сөеп карачан, әйтерсең лә, бөтен сөйкемле егетләр генә атка атлана! Ат яраткангадыр, мөгаен, гомер буе хыял аты – Акбузатта җиләм мин. Алтын тояклы, дулкын-дулкын яллы хыял аты мине матур чынбарлыкка илтә. Атлар кешнәгән яшел болында җиләм мин бүген дә.

## БАЛАН ТӘЛГӘШЛӘРЕ

(Нәсер)

Бакчадагы балан тәлгәшләрен сындырыр вакыт җитте. Күр әле, ботаклар сыгылып төшкән бит, балан уңган, кып-кызыл җимешләр эре булып өлгергәннәр, и тәмле дә булачак балан бәлеше! Балан катыгы тагы да тәмлерәк була, ә вареньесы аннан да тәмлерәк! Әйе, балан җимеше ачы җимеш, тел өстенә

салып тәмләп-тәмләп йота торган җимеш түгел ул, пешкәч кенә телеңне йотарлык була, хуш исле ризыкка әйләнә. «Ходайның рәхмәте, һәр җимешнең үз яме, үз тәме, шушы баланны гына әйт, нинди ачы, ә үзе матур, чәчәге дә үзгә, брошка итеп түшкә кадарсың!» – дип сөйләнә-сөйләнә әнкәй балан бүкәнли иде күзләр җиткән саен. Бакчабызда балан агачы берничә, тик кызарган балан тәлгәшләрен инде әнкәй куллары сындырмый, күзләремдә ачы яшь калдырып әнкәем дөнья куйганга да байтак еллар үтте. Баланнар үсә, бәлешләр пешә, тик әнкәй бар чактагы еллар сагындырып үзәкне өзә, юк, ул еллар онытылмый! Ап-ак карлы кыш ае иде, әнкәй түң балан чистартып бәлеш әзерли, бер авылдаш апа килеп керде, ул балан яратмый икән, «Әбәү, ачы бит ул балан!» – дип йөзен чытты. «Балан ачысы нәрсә ул, шикәр тәмле бит аны, ачысы калмый, яратып ашыйбыз!» – диде әнкәй. Белмим, ничә ел үткәчтер, шул апа безгә килеп үксеп елады: «Әй, Тәскирә апакаем, дөрес әйткәнсең, балан ачысы ачы түгел икән ул, кайгы-хәсрәт ачы икән!» – дип өзгәләнеп әйткән сүзләре бүген дә ишетелә кебек. Әнкәй балан ачысыннан ачырак булган тормыш җимешен татыган иде шул инде, белә иде, минем авыр язмышым иң ачы җимеш булды әткәм-әнкәм өчен.

Тугыз аеннан тәпи китеп, йөгереп йөргән сабый аякларына басалмас булсын әле, әй, бу язмыш! Күз яшьләрен гел генә күрсәтмәде әнкәй, минем күңелемне төшерәсе килмәде, шуңа да рухым сынык түгел, балан ачысына да йөз чытмыйм, ачырагы татып каралган! Кайгы ачысына тиң ачы юк, аны шикәр белән тәмләп булмый, шулай да кеше түзә, кайгылар күптөрле булса да кеше җиңә алмаслык кайгы юк, ачысын да, төчесен дә белер өчен яраткан без – бәндәләрне Аллаһы Тәгалә, сабыр итәр көч тә биргән үзе. Көз җитеп бакчабызда балан кызаргач уйларым тирәнәя, күңелемнән мәрхүмә әнкәем белән сөйләшәм, кайгы-шатлыкларымны уртаклашам, чынбарлыкта кебек бар да. Карашларым кып-кызыл балан тәлгәшләрендә, әнкәмнең тавышын ишетәм: «Балан ачысы нәрсә ул!» Язмышташларымның әнкәләре дә нәкъ шулай әйтә

торганнардыр, баласы өчен ачы күз яше түгә бит алар. Көзнең кояшлы көннәре, баланның сары яфракларын җилфердәтеп кызыл тәлгәшләрен тирбәтеп җил исә, талгын җил пышылдап кына әнкәм сүзләрен кабатлый: «Балан ачысы нәрсә ул!» ...

## ИКЕ ХАТ

(Нәсер)

Фотода Шәмсия әбинең оныгы Рәниф. Ул "Мәңгелек ут" янына чәчәкләр сала. Кар явып торган икән ул көнне, эре кар бөртекләре яшь солдатны әйләнеп очканда кадрда торып калганнар. Хатында мондый юллар бар:

"Совет Армиясе көнен күңелле бәйрәм иттек. Ул көнне миңа һәм ике иптәшемә ял рөхсәт иткәннәр иде, шәһәр карап йөрдек. Смоленск бик матур шәһәр, күп кенә җирләрендә булырга өлгердек. Фотода күрүегезчә, "Мәңгелек ут" янында да булдык, бер иптәш үзе белән фотоаппарат алган иде, мине төшереп алды. Халык күп иде, бар да чәчәкләр белән килгәннәр. Сугыш солдатының елаганын үз күзләрем белән күреп нык дулкынлану кичердем мин ул көнне. Шушы җирдә сугышкан ветераннар җыелган иде анда. Арадан берсе генә булса да Зур әтине белгәндер кебек тоелды. Минем хәтта: "Кадерле сугыш ветераннары, кайсыгыз Нургаянов Нуриханны белә иде? Ул минем Зур әтием. Ул да монда сугышкан, танкист булган, шушында үлеп калган!" – дип сорыйсым килде!" Шәмсия әби оныгының хатын күкрәгенә кыса. Калтыранган куллары белән күзләрен сөртә: "И балакаем, Зур әтиеңне күреп белмәсәң дә исеңә аласың бит әле, әй, үскәнкәем, исән генә кайт инде берүк, Зур әтиең кайталмады шул, кайтмады" Ничәнче тапкыр инде аның иреннәре шушы сүзләрне пышылдый. Күзләре талганчы фотодагы оныгына карап тора. "Рәхмәт улым, рәхмәт чәчәкләр өчен!" Шәмсия әби әледән-әле фотоны кулына алып

карый, хатны кат-кат укыта.Ританың мәктәптән кайтуын бүген дә көтеп алды, хатны кабат укыдылар. "Рәнифкәем, улыкаем, нигә шунда берәрсеннән сорамадың соң, Зур әтиеңне белүче булгандыр, булмый булмас, танкысы эчләрендә үлде микән, яраланып микән, янып микән, күргән булсалар сүләрләр ие үзеңә!" Шәмсия әби күңеленнән шулай сөйләнде фотодагы солдат оныгы белән.

Шәмсия әбинең кулында ике хат, берсе оныгыннан, икенчесен ул сандык төбеннән алды. Өчпочмаклы хат, кәгазе саргайган, өч баласын кочаклап, ирен зур яуга озатып калган, "Кайтыр!" – дип көтсә дә кулына кайгылы хәбәр китергән кара кәгазь генә алган тол хатынның сагышлары сеңгән ул өч-почмаклы хатка. Күп еллар үтте шул, утыз яшьтә тол калып, күп авырлыклар кичерергә туры килде. Ачлык, ялангачлык, ул елларны искә алуы да авыр. Фашистлар да җиңелде, тормыш авырлыгы да җиңелде. Балалар үсте, укып кеше булдылар. Гомер үтә икән, әллә җил булып исә, әллә су булып ага! Әтисе киткәндә 8 яше дә тулмаган Рәшитнең улы Рәниф икенче ел хезмәт итә бит инде. Еллар үтеп олыгая барган саен үткәннәр ешрак искә төшә икән. Нуриханы белән бергә үткән санаулы гына еллары әй, сагындыра. Вакытлар үтү белән онытылыр, дисәң дә онытылмый икән. "Кайтырмын, әнкәсе, сез көтсәгез кайтмый калмам!" – дигән сүзләре исенә төшеп өзгәли бәгырен. "Гүр салкыны суыта, сүрелдерә!" – диюләре, ахры, дөрес түгел. Көттеләр, көтми буламы соң! Күпләр көтте, шул ук вакыт кайтмаганнар да күп булды. Яу кырында күпләр калды. Шәмсия әби кулында өчпочмаклы хат, картының соңгы хаты, башка хатлары сакланмаган, ә менә соңгысын "соңгысы" икәнен белгәндәй, балалары да алып ертмаган, сакланган. Үле хәбәре килгәч ул хат бигрәк тә кадерле булып калды. Соңгы сәламе бит, соңгы сүзләре. "Шәмсия, балалар! Сугыш каты бара, без Смоленск дигән шәһәрдә, шәһәрне шәһәр дип әйтүе дә кыен, бик нык җимергәннәр, сволочлар, исән җире бик аз. Монда хәлләр коточкыч, шулай да җиңәрбез кебек, шуңа тырышабыз.

Рәшитнең гармун уйнарга өйрәнүе теләге мине шатландыра, өйрәнсен, син, әнкәсе, гармунны ватар-мазар, дип курыкма, бир, ватылса, сугыш бетеп, исән-сау кайтсам өр-яңасын алып уйнарбыз, өч кабат яраланып та үлмәгәч, инде үлмәм, кайтырмым!" Шәмсия әби, соңгы хаттагы бу юлларны яттан белә. Күзләре әйбәт күргәндә ул бу хатны еш укый иде, кәгазь саргайган, язган сүзләр тоныкланган. Ә күңелдә җуелмый, берсе дә җуелмый, саклана.

Шәмсия әби ике хатны да кадерләп кенә сандыгы төбенә салып куйды, Рәниф оныгының фоторәсемен янә кулына алды, оныгы аңа: "Зур әнием, син минем өчен тамчы да борчылма. Илебез имин, күгебез аяз. Кабат сугыш булмаячак. Язгы ташулар бетеп, гөлләр чәчәккә бөреләнгәч минем хезмәт елым тула. Көтегез мин, кайтырмын!" – ди кебек. Шәмсия әби яшь аралаш елмая: "Кайт улым, исән кайт!" – ди.

## КАРЛАР ЯВА

(Нәсер)

Яшь дустым, синең нинди тойгылар белән яшәвеңне беләм мин. Ап-ак карлар яуган бүгенге көндә синең шатлыкларың чиксез. Күкрәгеңне тутырып салкынча саф һава сулыйсың, сине әйләнеп-әйләнеп кар бөртекләре оча. Кар бөртекләре синең чәчләреңә, керфек очларыңа килеп куна, сиңа рәхәт, син елмаясың. Урам тулып очышкан кар-күбәләкләрне учларыңа кундырасың килеп, кулларыңны сузып йөгерәсең, яңа яуган кар өстендә уелып-уелып калган синең эзләргә янә кар тула бара. Минем изге, якты теләкләрем ул, эзләреңә тулган ап-ак карлар! Кыш килүенә шатланасың. Әйе, кыш сиңа кар таулары бүләк итәчәк. Тиздән, бик тиздән сине кар тавы үзенә дәшер: "Чанаңа утыр, чаңгыңа бас, әйдә, җилдән җитез җилдер!" – дияр. Таудагы шат тавышлар арасында мин, әлбәттә, үземнең балачагым кайтавазын

ишетми калмам. Кар ява! Тирә-ягың ап-ак, җир өстендә, коймаларда, түбәләрдә ап-ак кар. Түбәләрне каплап алган карларга гына кара әле, син андагы карның боз-каләмгә әйләнәчәген, тамчылар булып тамачагын беләсең, тамчылар җырлый-җырлый тамачак, син тамчылар җырын бүген үк ишетә, ни турында җырлауларын белә аласыңмы соң? Әгәр бу шулай икән, мин синең өчен шатмын, син киләчәктә һичшиксез җырчы-композитор булачаксың. Кар астында калган кырларга карап син шаулап утырган игенне, җиргә иелеп тирбәлгән алтын башакларны күрәсеңме? Әгәр шулай икән, синең игенче булуыңа, туган җиреңне сөеп, аңа тир түгеп яшәячәгеңә шик юк. Әгәр син бәс сарган агач-куак ботакларында ямь-яшел яфраклар, карлы яланнарда аллы-гөлле чәчәкләр күрә беләсең икән, мин синең рәссам булырыңа ышанам. Рәссам гына да түгел, син гөлбакчалар үстерүче, тормышта бары тик матурлык кына иҗат итүче булырсың. Шагыйрь булырсың.

Карлар ява. Ап-ак карлар ява,
Энҗе-мәрҗәннәрдән тулы күңел.

Әйе, күңелең энҗе-мәрҗәннәрдәй якты, матур уйлар белән тулы булса гына синең киләчәгең бәхетле! Кар ява! Яусын, карлар яусын, ул безнең шаулап килер языбыз, шау чәчәкле җәебез, мул уңышлы көзебез!

## КИЧЕР МИНЕ, ӘНКӘЙ

(Нәсер)

Бернидән дә курыкмаска, матурлыкка ышанырга син өйрәттең мине, әнкәй, син өйрәттең.

Хәтерлим, бала чагымда куркыныч төш күреп елап уянсам, "Курыкма, я, курыкма, яныңда мин бар, мин!" – дип төштәге куркыныч нәрсәләрнең өндә булмаячагына ышандырып мине юатырга ашыга идең. "Караңгы төннәрдән курыкма!" – диден

син, төн үтүгә якты булып көн туачагына ышандырдың. "Җенпәри, убырлардан курыкма, алар юк, бу бары искелек калдыгы, борынгы әби-бабаларыбызның наданлыгы!" – диден, дөньяда туу, яшәү һәм үлем барлыгына ышандырдың мине. Әкиятләргә ышанырга куштың. "Тормыштан алынып язылга әкиятләр, тик андагы аждаһалар, сихерчеләр, кеше ашаучылар куркытмасын сине!" – дидең. Җилләрдә, давылларда күкрәгеңә кыстың мине, "Курыкма!" – дидең, җилдавылларның тынып калырына, тормышта моннан да көчлерәк, куркынычрак давыллар очравына, тик аларны да җиңәр көч барлыгына ышандырдың. Авыртудан сабырлыгым бетеп, иренемне тешләп елаганда, "Авыртулар басыла ул, син курыкма, менә хәзер үтеп китәр, тән сызлавы үтүчән ул, түз, чак кына түз балам!" – дидең, мин ышандым, син дөресен сөйли идең. Авырта, авырта, дигән сүзләрем белән йөрәгеңне күпме яраладым. Ул яралар сызлаганда ничек түздең икән үзең? "Күңел күген болыт каплаганда куркып калу, бу инде куркаклык. Болытлар тарала!" – дисең син. "Бүген томанлырак булса, киләчәктә атар таңнарның яп-якты булачагына ышан!" – дисең. Ышанам, әнкәй, ышанам. Хәлсезләнеп, җиңелдем инде, беттем бугай, дигәч, алларыма килгән авырлыкны җиңәр көчем барлыгына ышандырасың.

Түзмәдем, беркөнне серемне ачтым . "Ул миңа, яратам, диде!" – дидем. Син кинәт үзгәрдең. Калтыранып киттең шикелле. Күзләрең куркулы ачылды. Әнкәй, ни булды? Сораулы карашларым сиңа төбәлде. Күңелем әллә нишли, хисләрем йөрәгемә тулып таша. Күзләрем аны, тик аны гына күрә, җырларым да аңа багышлана. Болар куркыттымы сине, әнкәй? Ни өчен? "Кызым!" – дидең, иңбашларыма кагылып. "Бик сак бул. Яратсын ул сине, хисләргә артык бирелмә. Караңгы төннәр бик куркыныч, аулакта калудан курык син. Яратсын, ярата бит, димә, ышанма син берүк, ышанма. Уйна, көл, азагы үкенү, күз яше булмасын!"

Әнкәй, бу "Курык!" "Ышанма!" дигән чүзләрне син әйтәсеңме? Чынлап әйтәсеңме? Беренче кабат, "Курык,

ышанма!" – дисең әнкәй, мин зур ич инде, мин сабый бала гына түгел. Кичерә күр мине, әнкәй, кичер кызыңны. Әйе, син бу сүзләрне әйтергә хаклы. Мин курыкмыйм, мин ышанам, әйе ышанам. Үземә ышанам, хисләремә, килер көннәремә ышанам. Бу дөньяда чын ярату барлыгына ышанам. Курыкмаска, ышанырга син өйрәттең мине, әнкәй, син өйрәттең.

## КОШ ОЯСЫ

(Нәсер)

Быелгы җәй бик яңгырлы. Еш явып торган яңгырларны кайгылы күз яшьләренә охшатам. Шатлыктан кайгы күбрәк бугай, кайгысыз килгән көн юктыр ул, бәндәләрен кайгы белән сыный Аллаһы Тәгалә. Ул якты дөньяны шулай яраткан, кеше туа – бу шатлыкның чиге юк, кеше үлә – иң зур кайгы шул була инде, күтәрә алсаң күтәр!

Әлфия белән Рөстәм Уфадагы туганнарына барып, бәби күреп, көнендә кайтырга дип уйладылар. Матур итеп киенделәр, күчтәнәч-бүләкләрен алдылар. Алты яшьлек Зөлфия белән ун айлык Алия нишләп әти-әнисеннән калсыннар ди? Кызларын курчактай киендереп үзләре белән алдылар. Юл буена Зөлфия күңелле итеп сөйләште, әти-әнисенә сорау арты сорау яудырды. Бакчага йөри, ара-тирә бакчада өйрәнгән шигырьләрен сөйли, җырлап та ала, шатлана, көлә. Юл буендагы агачлар, иген кыры, күктә йөзгән болытлар – бар да кызыксындыра баланы, күпне беләсе килә. "Бу агачлар арасында аюлар, бүреләр бармы?" – ди ул куе агачлык күрсә. "Юк, кызым, анда озын колаклы куяннар, матур итеп сайрый торган кошлар гына бар!" – ди әнисе.

Бала тормышта күбрәк әкият күрә. Зур шәһәргә барып кергәч, андагы аллы-гөлле чәчәкләргә сокланып карый Зөлфия. Юк ла, аларның ишегалдында үскән гөл-чәчәкләр

матуррак, кызчык үзе дә су сибә бит түтәлгә, бик кызыкса да чәчәкләрнең берсен дә өзми, сеңелесе Алия кебек кечкенә бит әле алар, үссеннәр! Чәчәкләрне күрергә дип әллә каян ерактан күбәләкләр очып киләчәк, Зөлфия аларны куып уйнар. Алия да тәпи басты бит инде, тиздән йөгереп йөрер, бергәләп күбәләк куарлар, әти белән әни кеше шатланып карап торырлар.

Көн кичкә авышты, кунак булып, бәби күргәч, Рөстәм кайтырга дип машинасын кабызды, туганнар белән хушлашып юлга кузгалдылар. Зөлфиянең шундый кайтасы килде, матур-матур рәсемле әкият китаплары да, тубы да көтәдер инде аны, зәңгәр күзле, бөдрә чәчле курчагы да сагынгандыр, кызчык аны кочаклап алачак. Күр әле, нәниләре Алия да кулларын чәбәкләп шатлана, туган җир, үз оялары көтә, газиз җир бер көн эчендә сагындырган. Кызлар йокларга уйламыйлар да шаяралар, көләләр. Зөлфия кайтып җиткәч тә урамдагы бергә уйнаган кызларга, малайларга Уфаданиләр күргәнен сөйлиячәк, көчтәнәчләр өләшәчәк. Алар кайтып җиткәндә кояш та кызыл тупка әйләнеп тау артына тәгәрәр шул инде, караңгы төшәр. Әйдә, зур шәһәр турында иртәгә, уйнарга чыккач сөйләр әле, онытмый ул аны. Юлда машиналар шундый күп, алга киткәннәре бар да Яңавылга кайтадыр инде, каршыга килгәннәре дә күп, әй, шәп йөриләр, куркыныч! Әнә, каршыга бер машина очып дигәндәй килә, ай, килә бит, ай, куркыныч, Зөлфияләргә килеп бәрелә бит инде. Ай!

Җил генә исә кебек иде, давыл икән шул, давыл купты, агач башындагы кош оясын җиргә алып бәрергә көче җитте аның, бер оя кош һәлак булды. Беркайчан да яшел тирәкләргә кунып сайрый алмаячаклар бу кошлар, нинди кызганыч! Әйе, тормышта кызганыч хәлләр күптөрле шул. Юл фаҗигасенә дучар булган Әлфия белән Рөстәмнең, аларның мәхәббәт җимешләре Зөлфия белән Алияның коточкыч язмышын ничек оясы белән һәлак булган кошларга тиңләмәссең, игезәк язмыш, игезәк күрәчәк.

Кошларга табигать явызлыгы үлем китерсә, кешеләргә эчкән, исерек бәндәләр үлем китерә. Зөлфияләрнең каршысына килгән машинаның руль артында исерек кеше булган. Июль таңында Яңавыл халкын кара хәбәр тетрәндерде. Өлкән яшьтәге ата белән аналары, туганнары, күршеләре, дуслары, хезмәттәшләре ничек кенә күтәрә алды икән бу кайгылы хәбәрне? Билгеле, Ходай ярдәм, сабырлык биргәндер, шулай булмыйча башка чара юк. Кояшлы дөнья, балкып торган йорт-ихата торып калды. Бер исерек бәндә аркасында бер матур яшь гаилә учагы сүнде, мәңге кабынмаска сүнде, гаилә учагы күз яшенә әйләнде. Ул көнне дә яңгыр әллә ничә тапкыр явып үтте, бу юлы табигать кайгыдан үксеп яшь түкте кебек. Әйе, нәкъ шулай булды. Мәрхүмнәрне соңгы юлга озатканда кояшлы иде. Ишегалдында үскән гүзәл чәчәкләр яктылыкка үрелеп елмайдылар. Бу матурлык Әлфиянең, Рөстәмнең, Зөлфиянең, Алияның җаны булып, кешеләр күңеленә иңеп калды. Бу яшь гаиләдән түтәлләрдә чәчәкләр үсеп калуы, әлбәттә, дөнья бар, яшәү бар, дигәнне аңлата. Тик куркыныч үлем дә бар шул, дүрт табутта әле яши генә башлап, инде сулышлары өзелеп калган Әлфия, Рөстәм, Зөлфия, Алия ята, вакытсыз өзелгән чәчәкләр алар, юк шул, терелмәячәкләр, оҗмах чәчәкләре булсыннар!

## КУРЧАК

(Нәсер)

И, Ходаем, нигә син аларны шундый ачы язмышлы итеп яраттың? Берсен генә дә түгел бит, икесе дә кеше ярдәменә мохтаҗ. Иңнәрдә язмышның таудай авырлыгын күтәрәләр, сызланып –сыкранып булса да тормыш юлыннан алга баралар, туктап, егылып калырга теләмиләр. Күкрәкләренә каккан җилдавылга бирешәселәре килми, бөгелсәләр дә сынмый әле

алар. Их, берсе көчлерәк булса! Хәер, алар икесе ике язмышлы булсалар берсен-берсе белмәсләр дә иде. Язмышлары игезәк булганга очраштылар алар, Ходаем, син үзең насыйп иттең. Һәркем үз тиңенә пар. Берсен-берсе таптылар да, яраттылар. Сау-сәламәт кешеләр көнләшерлек алардагы мәхәббәт! Рәхмәт, тәңрем, бу икәүнең йөрәгенә сөю биргәнең өчен. Ялкынланып сөйгән өчен алар көчле рухлы. Сөю аларны канатлы иткән. Уйлары изге, өметләре якты, хыяллары матур бу икәүне бөтенләй үк бәхетсез диеп булмый, ярма бөртегедәй генә булса да бәхетләре бар аларның һәм алар шул бәхеткә канәгать. Кешеләр машина алып утыра, әллә ничә катлы өй төзи, келәм алып элә һәм үзен бәхетле саный, бу ике җан иясе өчен инвалидлар коляскасын бер-берсенә якын китереп сөйләшеп-серләшеп утыру да чиксез бәхет! Икесе ике авылда яшәсәләр дә очрашалар, шатланалар. Туганнары ярдәмгә килмәсә, көзнең сары яфрагына әйләнер иде алар, рәхмәт яугырлары, егетне күтәреп машинага утырталар да кыз янына, кызны егет янына алып баралар. Бергә булырлык хәлдә түгелләр шул, матур яшәрләр иде. Сәламәтлегенең кадерен белмәгәннәр, ялгыз гомер иткәннәр, гаилә ямен китәргәннәр аларның ачуын китерә. «Их, бездә булсын иде шул сәламәтлек!» – диләр алар тешләрен кысып. Гаиләдә бер яки ике бала күреп «Безнең балалар күп булыр иде!» – ди Зиннур Нурияга сөеп карап. «Әйе шул, 3 – 4 булырлар иде!» – ди Нурия. «Юк, алай гына түгел, өй тулы булырлар иде. Мин сине бик яратам, Нуриям, сиңа әйбәт ир, балаларга матур, үрнәкле ата булыр идем!» Бу сүзләрне пышылдап әйтә Зиннур. Нурия ышана, нәкъ шундый булыр иде Нурияның Зиннуры. Тормышта хыянәт, күз яше булмас иде. Бүген саф сөю белән сөя ич алар, аякларында йөри алсалар да шулай сөярләр иде. Берсен-берсе тормыш иптәше итеп саный алар. Бергә яшәмәсәләр ни, язылышмасалар ни! Ә никахны тирәккә кунган сандугач укыды инде. Бергәләп сандугачны тыңлаганда, Ходай кошының тавышын шундый изге дога итеп ишеттеләр.

И, Ходаем, җан өргәнсең син аларга, нигә җиргә нык басып атлап йөрми алар, нигә шул көчне бирмәдең? Нурияның – әни, Зиннурның әти буласы килә, нигә син аларны шул ләззәттән мәхрүм иттең?

Бер очрашуларында Нурия Зиннурга бүләк итеп курчак сайлады, сәер дә бу, егет кешегә кыз кеше курчак бүләк итәме?! Нурия тирән уйланды бу хакта, әйе, шулай кирәк. «Бүләгем сиңа менә шушы курчак, син аны үзебезнең мәхәббәтебез җимеше – кызыбыз итеп кабул ит. Ул тере, карынымда яралмаса да хыялымда, кайнар хисләремнән яралды», – диде Нурия дулкынланып. Зиннур шатланды «Матур кызыбызга матур исем кушабыз!» – диде дә курчакны үбеп алды. «Исеме Сөмбел булсын!» – диде Нурия, Зиннур хуплады. Инде алар өчәү, Сөмбелләре бар. Нурия үзен әни кеше итеп хис итә, Зиннур да үзен әти итеп тоя. Курчак беркайчан да «Әти-әни!» дия алмаячак, ә менә ике иҗекле тавыш бирүе «Әти-әни!» диюе кебек. Зиннур белән Нурияның мәхәббәтен тагы да ныгытты кебек курчак, «Бала – тормыш яме!» – диләр шул. Чын гаилә тормышында бала йә, әтисез, йә, әнисез торып кала. Ир белән хатын, яннарында уйнап йөргән сабыйларын кызганмыйлар, аерылып икесе ике якка китәләр дә, баланың күңелен сыңар канатта калдыралар. Менә шулар хакында уйлап: «Юк, без бу ямьсезлеккә бармас идек!» – диләр Нурия белән Зиннур. Җансыз курчакны да ташлыйсы килми!

И, Ходаем, син бу икәүне бигрәк ачы язмышлы иткәнсең лә. Гарипләрең күп, алар җанындагы матурлык тормышка күчә алсын иде. Сау-сәламәт булсалар, әллә бүтән булырлар идеме алар да? Юк, явыз булмас иде алар, никадәр матурлык хыялда гына кала! Ходаем, ярдәм бир, яхшы теләктә булып та шуны эшли алмау авыр!

## МАЙ АЕ ЧӘЧӘКЛӘРЕ

(Нәсер)

Мөхтәрәмә карчык яз айларын көтеп ала. Бигрәк тә май аен, әллә нинди бер ашкыну, якты өмет белән көтә ул. Еллар гына түгел, бер кеше гомере үтте бит инде, барыбер элеккечә, яшь чагындагы кебек, буранлы кышларның тизрәк үтеп китүен, яз җитүен көтә. Инде ничәнче тапкырдыр сандыгын ача солдат хатыны, сандык төбендәге хатларны алып күкрәгенә кыса. Саргайган хатларны кулына алу белән иренең тавышын ишетә кебек: «Мин госпитальдә ятам, борчылма, ярам төзәлеп килә инде!». Мөхтәрәмә артык кайгырмый, ярасы төзәлә икән бит, исән, Аллага шөкер! Янә иренең тавышы: «Мин янә сугышам, котлар очарлык хәлләр монда, үләләр, бик күпләр кире кайталмаячак, Мөхтәрәмә кадерлем, син мине көт, өметләрне өзмик әле, мин кайтырмын кебек, бишектә калган улымны баш очыма күтәреп шатланырмын әле мин. Улыбызны йөгереп йөри, сөйләшә дип язгансың, мин кайтканда хәбәр бирермен, каршы алырга басу капкасы янына икәүләп килерсез. Әле без ут эчендә!» Бу тавыштан соң ут җанны өтеп ала, сулыш алуы авыр булып китә, күкрәккә саф һава түгел, төтен, кан исе кереп тула сыман. Мөхтәрәмә карчык яулык очы белән күзләрен сөртә. Экраннардан сугыш турындагы кинолар караганда да елый ул, ничек еламассың, хатларда да шулар язылган ләбаса! Ире чынбарлыкта күргәнне ул кино итеп карый. Йөрәккәең ярылыр! Нишләп әле бөтен дөньяны ут алмаган, ничек туктатканнар ул вәхшилекне?! Менә бу хат иң зур өмет уятканы, әнә шул өмет белән яшәде инде Мөхтәрәмә һәм Мөхтәрәмә кебек тол хатыннар. Хатыннар гына түгел, ата-аналар, балалар өмет белән яшәде.

«Минем кадерлеләрем, җиңү көне якынлаша! Исән-сау күрешербез дип ышанам, сез дә ышаныгыз, без фашистны өненә куып китердек. Быелгы яз җиңү белән килә, алмагачлар

ап-ак чәчәккә төренгәч бәйрәм итәчәкбез!» Менә шушы сүзләргә ничек ышанмассың?! Шатлыктан ярсып типкән иде солдат хатынының йөрәге, әле дә элекке кебек бер өмет белән ярсып тибә түгелме соң аның йөрәге? Язлар килгән саен шулай өметләнеп, көтеп типте йөрәк, тик солдат кына кайтмады шул, кайталмады. Үле хәбәре килсә дә көттеләр аны, алмагачлар чәчәк аткан саен көтәләр. Мөхтәрәмә карчыкның чәчләренә алмагачның ап-ак чәчәкләре сибелгән кебек, чәчләр агармаслык булдымыни, ялгызлык, ялгыз бала үстерү, илле ел буе әллә кайтыр дип өметләнеп көтү! Әйе, үлгәннәр кайтмый, ә бәлки үлмәгәндер, авыр яралар алып озак дәвалангандыр, кайтыр юлы ураудыр. Җиңү якынлашканын белгән бит, җиңү язы килде көтегез дигән! Җиргә бәйрәмле яз килде, илленче тапкыр килде ул, илленче тапкыр Мөхтәрәмә һәм аның кебек көтә белгәннәр матур киемнәрен киеп урамга чыгалар. Соңгы елларда басу капкасына ук баралмый Мөхтәрәмә карчык, урамга чыга, сугыш яланында калганнарга һәйкәл бар, шунда чәчәкләр илтә. Илгә иминлекләр тели-тели һаман юлларга карый.

## СИН ЯЗГАН ХАТЛАР

(Нәсер)

Синнән килгән хатларны кат-кат укыйм, укып туймаслык хатлар язасың, шатландырасың мине. Рәхмәт! Синең хатлар һәрчак тере, синең тавышың бар анда, мин аны ишетәм, тавышың да, йөрәк тибешең дә, шундый якын, кадерле булып ишетелә миңа, әйтерсең лә, син еракта түгел, янымда гына. Синең ялкынлы хатларың якынайта безнең араны. Яратасың! Кышкы салкыннар да куркытмый мине, синең хатлар килеп тора, җылы хатлар! Тышта кар-буран, ә минем күңелдә язлар балкышы, син миңа: «Карлыгачым!» – дип эндәшәсең, мине канатлы кошка әйләндереп кояшлы, зәп-зәңгәр күк киңлегенә

чөясең. «Чәчәгем син!» – дисең дә, сары яфрак очкан күзләрне, салават күпере нурлары белән балкыган җәйгә әйләндерәсең. «Кояшым!» – дисең син мине, күңел күгемне каплап алган күксел болытлар шунда ук таралып бетә, күңел дөньям нурга тула. «Мәхәббәтем!» – дигән саен, күз яшьләрем ләйсән тамчылары булып гөлләргә тама сыман. Син миңа хатларыңда шулай эндәшәсең. Синең сүзләр тере су булып иреннәремә тия, назлы җил булып чәчләремә кагыла. Сүзләрең күзләрең булып мөлдерәп минем күзләргә карый. Күзләреңдә моң бар, сагынасың! Сагыну белән бергә синең күзләрдә яктылык та күрәм мин, ул, өмет яктысы, өметең исән, димәк, алдагы көннәр безне очраштырачак! Хатлар барын да сөйли, хатларда синең сулыш! Яз, кадерлем, барын да яз, борчылсаң да, шатлансаң да яз, нинди төшләр күргәнеңне дә миңа хәбәр ит. Бакчалар чәчәккә күмелгәч төннәр салкын булганда, чапкан печән, урган ашлык яңгырларда калганда, кыр үрдәген аткан тавыш ишетелгәндә, без бергә борчылабыз. Гаиләләрдә бәби туе үткәрелсә, яңа йортлар күтәрелсә, авырулар терелеп аягына басса, күп еллардан бирле күрешмәгән дуслар, туганнар очрашса без чиксез шатланабыз. Менә шулай уртак безнең һәр нәрсә, син язасың, мин язам. Хатлар!... Хатлар!... Иң кирәк сүзләр тезеп кенә языла синең хатлар, әйтерсең лә, хат түгел, шигырь язасың! Яз! Синең барлыгыңа шатланам, хатларыңны куанып укыйм.

Тилмереп хат көткәннәр бар, җылы сүзләр белән язылган хатлар көтеп күпме җаннар өшеп калтырана! Нигә язмыйлар! Көткәннәрнең барысына да их, килсен иде ул мәхәббәт хатлары. Сагынып язсыннар иде! Син язасың, синең хатлар борчулы булсам юата, авыртынганда дәвалый, синең хатлар белән яшим мин. Килгән кыенлыкларны әнә шулай бергә җиңәбез. Син яз, энҗеләр итеп тез, барысын да яз, тик «Бу сиңа соңгы хатым!» – дип яза күрмә, язма андый хатны, кошкаеңның канатын каерма! Яз! Мин көтәм! Моңа кадәр әле бер тапкыр да яңгырамаган гүзәл җыр кебек итеп язган хатларыңны көтәм!

## ТУРГАЙ БУЛЫП КАЙТТЫМ

(Нәсер)

Кыш аенда ап-ак карларга карап юансам, җәйләр җиткәч, җанга шатлык кирәк булганда, мин кырларга чыгам. Басу юлыннан коляскамны этеп баручы туктый да юл буенда үскән чәчәкләргә кулын суза, миңа өзеп бирмәкче ул, юк, мин өздермим. Җаныма рәхәтлек табар өчен табигать кочыгына ашкындым, миңа бар да тере килеш кирәк! Бераз юл үткәч тукталып тирә-ягымны күзәтәм, күкрәгемне тутырып-тутырып басу һавасы сулыйм. Мең төрле чиргә дә дәвадыр бу һава! Алдымда колачын киң җәйгән иген басуы. Башакларның талгын тибрәлеше дулкын булып йөгерә. Бу дулкыннарның килеп кагар яры – күңел! Рәхәт булып кага алар, күңел шатлана, сафлана, авыр уйларыннан арынгандай була. Күңелнең иң нечкә кылларын чиртә мондагы хозурлык! Игенчегә рәхмәт укый-укый басу исе исним. Икмәк исеннән дә тәмлерәк ис бармы соң ул, юк, мең төрле хуш исле чәчәгең бер якта торсын! Искән җилгә кушылып башак шаулый, аңа тургай кушыла. Кояштан түгелгән нурга канат очларын манып-манып, зәңгәр күк дулкынында йөзә бит ул сабан тургае! Бик рәхәттер аңа, әнә ич, өзлексез сайрый, кайгысы булса елар иде, ә ул –җырлый! Сабан тургае буласым килә. Юк ла, юк, миңа да рәхәт, минем дә йөрәгем җырлый! Йөрәгемне тургай итеп туган кырларым күгенә күтәрдем.

Мин сагынып кайттым, син дә мине<br>
Көтеп алгансыңдыр мөгаен.<br>
Газиз җирем, мин дә күкләреңә<br>
Күтәрелер сабан тургаең.<br>
Тургай җыры аша ишет әле,<br>
Йөрәгемнең ничек типкәнен,<br>
Кайда гына дисәм, инде белдем,<br>
Бәхетемнең синдә икәнен.

Тургай итеп мине алып кайтты
Туган җиргә булган мәхәббәт.
Рәхмәт сиңа, иген – диңгез өчен,
Зәңгәр күгең өчен, мең рәхмәт!

Монысы инде талгын җилләргә, алтын дулкыннарга кушылып агылган минем җыр! Туган җиреннән тамырларын өзеп чит җирләргә киткәннәр турында уйлыйм мин. Кайсылары озак еллар кайтып та әйләнми, әллә шулай туган җирне онытып та була микән? Юк, онытып булмыйдыр, Ходайның ул бәндәсе сагына гына белмидер, үтә дә ваемсыздыр! Бәхете тулы түгел бит инде аның, туган җирендә кырлар тулып тибрәлгән игеннәрне дә күреп шатлана алмый. Рәхәтләнеп сулыш алып яшәсә дә туган басуы исен белми аның борыны, тургай җырын колаклары ишетми, җаны шатлык тоймый. Ул бит, иген үстерүче, илгә байлык-муллык бирүче якташына, авылдашына рәхмәтен дә әйтә алмый, бу турында уйламый да ул. Шатланыр өчен кырларыма чыктым. Җир дә, күк тә шатлык булып җанга иңә!

## ТЫШТА ЯЗ

(Нәсер)

Буранлы кыш үтеп, язның беренче тамчылары тама башлауга барыбыз да куанабыз. Яз, өлкәннәрнең дә, балаларның да чиксез шатлыгы, күңел бәйрәме.

Язның матурлыгы көн саен арта бара. Һава җылына, җилләр назлы исә, гөрләвекләр җырлый-җырлый ага бу көннәрдә. Тәрәзә башы саен күк күгәрченнәр гөрли, ялангач куакларга кунып чыпчыклар чыркылдаша. Тупыл башлары чоп-чуар, кара каргалар оя кора. Бу әле язның башлануы гына, алда әле аның шау-гөр килеп торыр чаклары. Сыерчыклар килгәч, елгаларда боз кузгалгач, басуга

буразналар сызарга тракторлар чыккач яз тагы да матуррак була.

Карны тишеп чыккан беренче чәчәге –умырзаялары, ямь-яшел, хуш исле бөреләре, җылы ләйсәне бар язларның. Хәер, язның матурлыгын санап кына бетерерлек түгел. Аны һәркем үзенчә күрә, тоя ишетә. Язгы аваз шагыйрьгә шигырь булып ишетелсә, композиторга ул җыр булып яңгырый.

Барыбыз да язны көтеп алабыз. Яз килүенә шатланып туймыйбыз. Тирә-ягыбызны язгы матурлык бизи. Бар матурлык янибызда гына икән. Кояш баш очында гына, гөрләвекләр аяк астында гына, җилләре үзеңә уралып йөри, чәчәкләре үсү белән: “Кулыңны суз!” – дип тора.

Ә кошлар. Язның кошлары да бар. Кошлары булмаса яз яз булмас иде. Капка баганасына кадакланган оясы түбәсенә кунган сыерчыклар бер сызгырып җибәрүе генә дә үзе ни тора! Яз, дигәч тәүдә ерак сәфәр киткән канатлы дусларыбыз искә төшә. Яратабыз кошларны, кайтуларын сагынып көтәбез. Әле мин кошлар турында “Дусларыбыз”, “Яратабыз!” – дидем. Дуслык, ярату турында сүз башлавым юкка гына түгел.

Укучылар, нәни дусларым! Сезгә сорау бирәсем килә. “Кошларны яратасызмы? Барыгыз да яратасызмы? Әйе, барыгыз да бертавыштан “Яратабыз!” – диярсез. Тик беләсе иде , ничек яратасыз микән?

Кошның зәңгәр күккә күтәрелеп канат җилпи-җилпи очканын күзәтү, куакларга кунып иртә-кичен сайравын тыңлау, оясыннан егылып төшкән нәни кошчыкны яки имгәнгән кошны кызганып кулларыңа алу, җылы тыныңны өреп иркәләүләр генә әле бу кошларны ярату түгел. Кошларны ярату – синең кошлар турындагы хәстәрлегең, аларны көтеп ала белүең. Сез аларны ничек көтәсез икән? Бик ерактан, күпләребез китаплардан укып кына, кинофильмнардан күреп кенә белгән ерак иллердән кайта бит алар. Юллары ерак, авыр кошларның. Ераклык та, авырлык та куркытмый аларны. Кайталар, туган-үскән, канат ныгыткан җирләрен сагынып кайталар.

Нәни дусларым! Кошларның чын дуслары була беләсезме? Килүләренә яңа оялар ясап элдегезме? Искеләрен буяп, төзәтеп куйдыгызмы? Малайлар! Кошларга умарталар ясыйсызмы, рогаткалар түгелме? Кызлар! Җимнәр сибәсезме, ашатасызмы кошларны? Онытмыйк без кошларны, каты бәгырьле булмыйк, кунак көткән кебек көтик үзләрен. Алар безгә җыр алып кайта, без аларның җырларын тыңлый-тыңлый язларда, җәйләрдә яшибез.

Тышта яз. Матурлыкка соклана белү генә аз, матурлыкка күңел матурлыгыңны өсти белсәң, тормыш тагы да гүзәлрәк булыр. Кошлар кунып сайрар ботакларны сындырмыйк. Табигатькә карата бөреләнеп кенә килгән мәхәббәтең шаулап чәчәк атсын, нәни дустым!

## УРАМ
(Нәсер)

Дүрт кенә йорттан торган бу урамның шау-гөр килеп торган чагы бар иде. Тып-тын хәзер монда, агачлар шаулавы гына элеккечә. Мәрхүм Ясәви бабай утырткан ак каеннар шаулый монда, Әхмәтнур Ак бабайның имәннәре шаулый. Тупылы да, чаганы да, шомырты да, сирене, миләше, чыршысы да бар безнең урамның. Әле гөлҗимеш куагы шау чәчәктә, өч ел элек гүр иясе булган әнкәем орлыктан үстергән иде оларны, «Чәчәге матур, җимеше тәмле!» – ди иде. Гөлҗимешнең баллы җимеше үзебез өчен генә булмады, шушы урамда уйнаган һәр бала, үтеп китүченең һәрберсе диярлек җимештән авыз итте. Куак килер көздә дә җимешле булыр, тик кемнәр генә өзәр, Тәскирә апаларын искә алып җимеш өзәрдәй бала-чага да юк бит урамда! Фәрит абый белән Фәгыйлә апа биш бала үстерделәр дә, күрше авылга күчеп киттеләр. Сау-сәламәт булып, матур булып үсеп килгән балаларын күреп: «Урам яшәячәк икән әле!» – дип

шатлануым гына иртәрәк булган, киттеләр бит, күңелдә бала чаклары гына торып калды. Киттеләр, бер оя сиреньнәре һәм буш өйләре моңаеп утырып калды. Рәхмәт, тәрәзәләрен такта белән кадаклап урамны ямьсезләмәделәр, тәрәзәләр челтәр пәрдәле килеш бүген дә. Аннан-моннан килгән кешеләр: «Анда кемнәр яши?» – дип сорый, ташландык йорт икәнлеген беркем белми. Йорт-җирләрен калдырып бер-бер артлы Ак әби белән Ак бабай да дөнья куйды. Алты якка киткән алты бала шушы урамда, яшел чирәмдә аунап үскән. Йортта беркем дә яшәми, поселокта яшәүче кече кыз дача итеп тота бу йортны, бакчасында җиләк-җимеш өлгерә, хуҗалар сирәк күренсәләр дә ничектер, яшәү дәвам итә кебек. Тик менә ул йортның да тәрәзәләрендә ут булмый шул, килсәләр дә ашыгып кына килеп китәләр, бер карыйсың, капка төбендә зәңгәр «Москвич!» тора, икенче карауга киткән дә була ул.

Урам, яшел урамкаем, синең гармунчың да бар иде. Ясәви бабайның «Батский» гармунда уйнавын еш ишеттең, урам. Җиде бала үстергән атаның җитмеш төрле уе булгандыр, ниләр генә уйламагандыр ул кулларына гармун алган минутларда! Балалар таралышып бетте, Сәгадәт әби ямансулап каеннарга карый. Каеннар шаулавы кайчакларда аңа гармун моңы булып та ишетелә торгандыр, Ясәвие истәлеге ич ул каеннар! Мин урамга чыгып шул бөдрә каеннар ышыгында утырырга яратам. Рәхмәт Ясәви бабайга, менә бит нинди матурлык калдырган, урамга яме дә, эссе көннәрдә ышыгы да бар каеннарның. Шушы каеннарның бөреләрен, җәен-яшел, көзен сары яфракларын күңел моңыма төреп җырлап яшим мин. Авылны урап кайтам да: «Иң матур урам – безнең урам!» – дим. Әйе, иң матур урам безнеке, бүген дә ямь-яшел, матур әле ул, тик шау-гөр килеп тормый. Үткән еллар, ямьле еллар бүген килеп күңел кылларына сагыш булып сарыла. Кояшның да, Айның да якты нуры бар урамда, тик менә безнең балачагыбыз юк анда, ул чактагы якты уйларыбыз томандай таралган. Берәү дә үз нигезен кормады, урамны яшәтү турында уйламады. Урамның гомере кыска,

гомер чигенә җитеп килә ул, коточкыч! Безнең дә гаилә җәйгә генә кайтты монда. Юк, китмәс идем мин, тормыш аерды мине туган җирдән. Авылымнан, урамымнан, күп еллар яшәгән өебездән чыгып китүләре газаплы, ә китми калып булмый. Урамга хуҗа булып Сәгадәт әби кала. Исән-сау булсын әле, ул яшәсә урам да яшәр, безгә дә кайтып йөрергә насыйп булсын. Бөдрә каенлы урамны әрем, кычыткан басмасын иде, юк, урамны бетерәсе килми, оя корсын иде шушында бер яшь гаилә, киләчәктә шау-гөр килеп балалар уйнасын иде шушы урамда, әйдә гел: «Безнең урам!» – дип әйтсеннәр иде, «Мин дә шушында яшәдем, гомеремнең аллы-гөлле еллары монда үтте!» – дип мин җыр гына язар идем. Кыл өстендә яши урам, нигез ташлары гына калачак бу урамда. Әткәй утырткан алма агачларын кычыткан урап алыр, «Бу татлы җимешләр үскән бакча урыны!» – дип, ярый ла, оныклары искә алса! Бетә, озакламый бар да бетә. Матур картина булып хәтердә генә кала бу урам, йорт-җир! Йөрәк үкси, өметсезлектән дә ямьсезрәк берни дә юк икән ул. Өметсезлек салкын да, караңгы да икән!

Мин урамда, урамда үткән еллар кайтавазы булып, магнитофон тасмасыннан Ясәви бабай уйнаган авыл көйләре яңгырый. Моңа кушылып, әнкәйнең каз-үрдәкләр чакырган тавышы һәм бала-чагаларның шаулашып уйнаулары ишетелә.

## ЯЛГАН МАТУРЛЫК!

(Парча)

Сау-сәламәт, төскә-биткә карап торырлык чибәр хатын. Чама белеп кенә буянган, өс киеме бик күркәм бу хатын, игътибарымны үзенә җәлеп итте. Шушында туып-үскән кыз иде ул, ерак шәһәрдән тормыш иптәше белән кунакка гына кайтканнар. Инде күптән күргәнем юк иде, үзгәрмәгән, авылдашым һаман да кырларым чәчәгенең берсе ләбаса!

Уйларым тирән, уйларым якты. Кояшлы көнгә, чәчәкле гөлгә тиңлим мин чибәр хатын-кызны. Дөньяны якты итүче кояш булса, тормышны ямьле итүче – хатын-кыз матурлыгы! Төсе матур хатынның теле дә, уй-хыяллары да, эшләгән эше дә матур булырга тиеш һәм бу шулайдыр дип уйлый идем мин, ялгышканмын. Миннән бер читтәрәк торган хатыннарның сөйләшүен ишетәм:

– Күптән кияүгә чыккан идең, бәбиегез кем, кызмы, малаймы?

– Беркем дә юк, мин бала яратмыйм! Кунакка кайткан авылдашымның бу сүзе минем җанны гына түгел, зур дөньяны тетрәтте кебек. Чибәр хатынның йөзенә карыйм, йә, Ходай, шул арада чәчәкләргә тиң булган матурлык кая булды, бер генә тамчысы да калмады, әллә су булып акты, әллә җил булып исте, юкка чыкты. Әйтерсең лә ул матурлык булмаган, хатын кара көеп, шиңгән чәчәккә охшап калды. Кояшны болыт каплады, дөнья караңгыланды, коточкыч давыл купты, бу давыл агач ботакларын түгел, күңел тирәкләрен сындырып, тамырыннан куптарып ташлый торган давыл, исән нәрсә калмас кебек. Мин ялган матурлык белән очрашканмын икән, ялган матурлык тормышны ямьле итә алмый. Күз алдымда чибәрлеге эреп аккан хатынның тормышы ямьле димәс идем, ярата белмәү ничек ямь булсын! Бала яратмаган кеше кемне һәм нәрсәне ярата алсын?! Бала – ул бит якты, матур киләчәк! Бала яратмагач киләчәге юк ич ул хатынның. "Балам юк!" – дип өзгәләнгән хатыннарны беләм мин, бала яратмаганнарын очратканым юк иде. Көләрсең дә, еларсың да, акылсызлыктан арынып бетәлмисең шул әле әй, тормыш! Сабыен кулларына күтәреп елмая, тезләренә утыртып сөя, иркәли, бәләгенә куеп күкрәк сөтен имезә, бишек җыры көйләп йоклата, хатын-кызның гүзәллеге менә кайда! Ул – ана, ул – бәхетле, ул – кеше! Дөньяны ана шатлыгы кояшлы–айлы итә, бала көлүе тормышка былбыллы яз китерә! Котырынган давыл тынычлана төште, кояш нурлары да сибелде, чөнки хатыннарның берсе: "Балам йокыдан уяныр инде!" – дип кайтыр юлына чыкты, ана йөрәгенең "Балам!" – дип типкәнен мин дә, дөнья да ишетеп тордык. Бала яраткан хатын-кызлар дөньяның исәнлеген саклап мәңге яшәр!

# СОДЕРЖАНИЕ


БЕЗНЕҢ ОКТЯБРЬ... 2
УЙЛАРЫМ ДӘРЬЯ... 4
ЙӨРӘГЕМДӘ ЯЗ ҖЫРЫ... 5
ГӨЛЛӘРГӘ СУ СИБӘМ ӘЛЕ... 6
ӨЗЕЛГӘН ҖЫРЫМ... 8
ЯФРАК ЯҢГЫРЫ... 10
ТӨН... 12
ЯҢА КЕШЕ... 13
ЯСАЛМА ЧӘЧӘКЛӘР... 15
БҮЛӘК... 16
БҮГЕНГЕ ҖЫР... 17
КҮКЛӘРЕҢ БОЛЫТЛЫ, АЯЗ!... 19
БӘХЕТ... 22
БӘХЕТ ТУРЫНДА ҖЫР... 23
КӨТӘРГӘМЕ СИНЕ?... 25
БӘХЕТЛЕ АНА БУЛ... 26
КӨТӘСЕҢ... 28
СӨЯРГӘ КИРӘК... 30
КҮБРӘК АНАЛАР ЕЛЫЙ... 31
КАЙТЫЙК ӘЛЕ!... 33
МӘХӘББӘТ КОШЫ ҮЛГӘН!... 34
ҖИРДӘ ЯЗ!... 36
СҮЗЕМӘ ЫШАН... 38
ЧИШМӘ СУЫ... 40
СӘЛАМ ӘЙТ... 41
ТӘРӘЗӘЛӘР... 43
КОШЛАР КИТӘ... 45
АПРЕЛЬ ҖИЛЛӘРЕ... 46
АЧЫ ҖИМЕШЛЕ ЯЗМЫШ... 48
ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ... 51
АПРЕЛЬ ҺӘМ МИН... 53
АВЫЛ... 54
АК ЧУК, КАРА ЧУК... 57
АП-АК КАРЛАР ЯУГАНДА... 58
АТЛАР КЕШНИ... 60
БАЛАН ТӘЛГӘШЛӘРЕ... 61
ИКЕ ХАТ... 63
КАРЛАР ЯВА... 65
КИЧЕР МИНЕ, ӘНКӘЙ... 66
КОШ ОЯСЫ... 68
КУРЧАК... 70
МАЙ АЕ ЧӘЧӘКЛӘРЕ... 73
СИН ЯЗГАН ХАТЛАР... 74
ТУРГАЙ БУЛЫП КАЙТТЫМ... 76
ТЫШТА ЯЗ... 77
УРАМ... 79
ЯЛГАН МАТУРЛЫК!... 81

Литературно-художественное издание

**Кәүсәрия Шафикова**

**ҖАН АВАЗЫ**

Нәсерләр
(татар телендә)

Редакторы *Ф.Ф. Аскарова - Галиева*
Техник редакторы *Ә.Г. Латыйпова*

Җыярга бирелде 02.07.07. Басарга кул куелды 7.07.07. Кагазь форматы А 5. Офсет кәгазе. Әдәби гарнитура. Ризографта басылды. Шартлы басма таб. 1,80. Учет-нәшер. таб. 1,30. Тиражы 500 данә. Заказ № 833. Хакы ирекле.

**ООО "НУР"**